2016 ел: сөенечләр һәм көенечләр

Узып баручы ел россиялеләр һәм татарстанлылар өчен нинди вакыйгалары белән истә калачак

4-5 БИТ

«2017 ел җиңелрәк булачак»

Экстрасенс Алсу Газыймҗанованың 2017 елга фаразлары: халыкның яшәү сыйфаты яхшырачак, өй туйлары күп булачак

9 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 29.12.2016 | № 143 (5761)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

РЕСПУБЛИКАДА

ӘЛКИ

Салман авылында ике катлы мәдәният йорты ачылды. 50 ел элек төзелгән бинаны яңарту өчен республикадан 10 миллион сум акча бирелгән булган. Мәдәният йортының түбәсе, идәнтүшәмнәре, тәрәзәләре тулысынча алыштырылды. Шулай ук җылылык системасы, суүткәргечләр яңартылды. Фойе, тамаша залы, артистлар өчен бүлмәләр зәвык белән ремонтланды.

ЯШЕЛ ҮЗӘН

Олы Ачасыр мәдәният йортында «Дин һәм сәламәтлек» оешмасы эшли башлады. Өлкән яшьтәге кешеләр һәр атнаның чәршәмбесендә дин юнәлешендә укысалар, шимбә-якшәмбедән кала, көн саен спорт секциясенә йөрергә дә вакыт табалар. Оешма җитәкчесе Тәскирә Шәйхуллина белән кичләрен Скандинавия йөрешенә чыгалар.

АЗНАКАЙ

Район урман хуҗалыгының 85 еллыгы уңаеннан «Азнакай урманчылыгы» оешмасы бинасында тарихи музей ачылды. Музей экспозициясендә күп кенә фотоматериаллар, китаплар, документлар архивы бар, шулай ук биредә Татарстанның атказанган урманчылары үз эшләрендә файдаланган кораллар саклана.

САБА

Пауэрлифтинг буенча Мәскәүдә күптән түгел үткәрелгән дөнья чемпионатында 60 килограммга кадәрге үлчәү категориясендә Саба районы егете Ришат Йосыпов дөнья чемпионы исемен яулады. Ришат 1989 елда Байлар Сабасында туган, хәзерге вакытта Казанда мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумында укыта.

ЧАЛЛЫ

Кама балалар медицина үзәгендә җиде меңенче сабый туган. Ир баланың авырлыгы – 3430 грамм, буе 53 сантиметр булган. Автокалага бала табарга Татарстанның ерак районнарыннан да киләләр, чөнки биредә шартлар яхшы, табиблар тәҗрибәле. Быел гына да биредә 1500ләп хатын-кыз бала тапкан. Чаллы бала туу буенча узган ел рекордын кабатлады дисәк тә була: монда 2015 елда 7017 нарасый дөньяга килгән.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

СЫЕРЛАРГА субсидия бетереләме?

Мәгълүм булганча, Татарстанда бер баш савым сыеры өчен – өч мең, кәҗәләр һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләре тотучылар өчен берәр мең сум субсидия түләнә.

Быел гына да республикадагы шәхси хуҗалыкларга шушы максатлардан 356 млн сум акча күчерелгән иде. Көнне төнгә ялгап эшләүче авыл халкына шактый ярдәм бу. Акмаса да, тамып тора бит. Ашаган белми, тураган белә дип, терлек асраучының нинди зур мәшәкатьләр һәм чыгымнар таләп иткәнен алар үзләре генә белә. Авылда башка эш урыннары булмаганлыктан, терлек асраучылар күп хәзер. Пай җирләрен үзләштереп, терлек азыгын да шунда әзерлиләр андыйлар.

Әмма шушы көннәрдә авыл халкы арасында, киләсе елдан сыерларга субсидия бетереләчәк икән, дигән имешмимешләр таралды. Әлеге сорауга Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Нәҗип Хаҗипов ачыклык кертте. Чыннан да, мондый проект бар, ләкин ул әлегә әзерләнеп бетмәгән, ди ул. Шуңа күрә алдан борчылырлык урын юк, дип тә өстәп куя. Хуҗалыклар узган елгыга караганда мал санын һәм бер сыерга булган сөт күләмен киметкән очракта, субсидия түләү туктатылырга мөмкин.

Министрлык китергән мәгълүматлар буенча, быел республиканың берничә районында маллар саны кимегән. Әлки районында мөгезле эре терлекләрнең саны якынча өч меңгә азайган. Баулыда бу сан – 990, Буада – 1600, Алабугада – 1000, Питрәчтә – 1000, Чистайда 2700не тәшкил итә.

– Маллар саны төрле сәбәпләр аркасында кими. Кайбер хуҗалыклар банкротлыкка чыга. Аннан соң, гадәттә, кешеләр көз көне терлекләрне ашатып симертәләр дә, аннан соң суеп саталар. Бу да малларның баш саны кимүгә китерә. Бозаулар, гадәттә, еш авырый, савыга алмыйча, үлеп тә китәләр. Шуңа күрә аларның санын арттыру юнәлешендә эшләргә кирәк, – ди ул.

Министр урынбасары сүзләренчә, мал санының артуы яки кимүе җитәкчелеккә дә бәйле.

– Бездә бик көчле, уртача һәм авыррак эшчәнлек алып бара торган хуҗалыклар бар. «Авыр бара» торган хуҗалыкларның саны 60-70 тирәсе. Калган 605 хуҗалыкның, узган елгыга караганда, күрсәткечләре шактый югары. Моңа бәлки сөт бәяләре дә тәэсир иткәндер, – дип уйлый җитәкче.

Ә менә сөт җитештерүгә килгәндә, аның күрсәткечләре, киресенчә, арткан. Ел башыннан алып Татарстанда сөт җитештерү өч процентка күбәйгән. 1 декабрьгә булган мәгълүматлар буенча, республикада 1 миллион 109 мең тонна сөт җитештерелгән. Шушы көннәргә әлеге күрсәткеч 1 миллион 203 мең тоннага кадәр җитәр дип фаразлана.

Шәһәр кәефе

НУРИСЛАМ НУРАДИМОВ,
пенсионер:

– Казанда 1954 елдан мин, әтумышым белән Саба районының Олыяз авылыннан. Себердә күперләр төзүдә катнаштым. Татарстан сагындыргач, кире кайттым. Казанда шактый еллар авиация заводында эшләдем. Пенсиягә чыккач та, егерме ел хезмәт куйдым әле. Борынгылар, хәрәкәттә – бәрәкәт, дип әйтеп калдырганнар. Ветераннар хорына йөрим. Алла боерса, киләсе елда да җырлап яшәргә исәп. Тормышта күңел төшенкелегенә бирелмәскә кирәк.

МАРИЯ НИКИТИНА,
студент:

– Киләсе ел минем өчен бик җаваплы ел. Диплом эшен уңышлы гына яклап чыгасы иде, хәзере белән. Чит илләргә сәяхәт планлаштырмыйм. Туган шәһәрем Зәйдә яки Казанда эшкә урнашасы бар. Укырга кергәндә бер дулкынлансам, хезмәт юлын башлау шулай ук уйландыра. Ту-154 очкычында һәлак булган Александров исемендәге ансамбль артистларын бик кызгандым. Киләчәктә мондый фаҗигаләр булмасын иде.

АЙГӨЛ ӘХМӘТШИНА,
журналист:

– Самара шәһәре кешеләре казанлыларга караганда күпкә гади һәм ачык йөзле тоелды миңа. Казанда бөтен кеше каядыр ашыга, дорфа җавап кайтаручылар да очрый. Авыр мохит ул кәефне төшерә, үзең дә соры массага кушылып, усалланасың. Йомырканы яшелчәләр, төрле тәмләткечләр кушып, тәфсилләп пешерергә яратам. Мин әле кияүдә түгел, матур һәм ышанычлы гаилә корырга хыялланам.

НАЗЛЫГӨЛ ГАЛИНА,
студент:

– Аллага шөкер, кәефләрем әйбәт. Сессия имтиханнарын биреп чыктым. Яңа ел каникулына туган ягым Азнакайга кайтам. Җәйгә иптәш кызлар җыйнаулашып, Сочига барырга хыялланабыз. Мин архитектор белгечлегенә укыйм. Казанның һәр районында бер генә булса да мәһабәт бина төзелсен иде. Кичләрен чигү чигәм: табигать күренешләре, чәчәкләр. Чигеп бетергәч, зур канәгатьлек хисе туа.

ДАМИР ШӘЙМУРЗИН,
тәрҗемәче:

– Гаиләбез югалтулар кичерде. Ата-ананың, туганнарның кадерен белегез. Киләсе елда халыкның тормыш-көнкүреше яхшырсын иде. Дөньяда тынычлык урнашсын, илебез икътисадына санкцияләр һөҗүме туктатылсын иде, дип телим. Француз, инглиз, испан телләрен беләм. Гарәп телен өйрәндем, ул бик катлаулы тел. Бер сүз күп мәгънәләргә ия, шунлыктан гарәп теленнән тәрҗемәгә сак карау зарур.

Исән каласың килсә, эчмә!

informaplus.ru

Татарстанда составында спирт булган, ашарга яраксыз продукция бер ай дәвамында сатылмаячак. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе социаль-гигиена мониторингы бүлеге җитәкчесе Әлфия Титова хәбәр итте.

Атна башыннан гамәлгә кергән әлеге чара Иркутскида «Боярышник» белән күп кеше агуланганнан соң кабул ителгән. Исегезгә төшерәбез, узган атна эчендә анда 120 кеше агуланды, шуларның 75е дөнья белән хушлашты.

Бу хәлләрдән соң Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе спиртлы эчемлекләр җитештерүче 40 оешмада тикшерү үткәргән.

– Без 18 проба сайлап алдык. Аларның 12се – парфюмер-косметика продукциясе, ә алтысы – көнкүреш химия товары. Хәзерге вакытта аларның барысы да тикшерелә. Нәтиҗәләр әлегә билгеле түгел, – диде җитәкче.

Хәер, Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисади куркынычсызлык һәм ришвәтчелеккә каршы көрәш идарәсенең бүлек башлыгы Ринат Акчурин сүзләренә караганда, мондый тикшерүләр һәрвакыт үткәрелеп тора. 2016 елда гына да исерткеч эчемлекләр сатыла торган урыннарда 27 мең тикшерү үткәрелгән. Нәтиҗәдә легаль булмаган әйләнештәге 250 мең литр ялган аракы һәм составында спирт булган сыеклыклар алынган.

Халык телендә «фанфуриклар» дип йөртелгән лосьон һәм тониклар эчеп агуланган кешеләр саны соңгы вакытта аеруча арткан. Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясе башлыгы урынбасары Рөстәм Арсланов китергән мәгълүматлар буенча, 2016 елның 11 аенда мондый сыеклыклар белән рөхсәтсез сату итүнең 338 очрагы ачыкланган. Административ тикшеренүләр вакытында алынган үрнәкләр лабораториягә җибәрелә. Ярлыгында косметика продукциясе дип язылса да, аларның 98 процентында спиртка су кушылган булуы ачыклана.

– Составында күп күләмдә спирт булган лосьон һәм тониклар арзан бәядән сатыла. Шуңа күрә алар кайбер категория кешеләр арасында аеруча популяр. Әмма мондый эчемлекләрне куллану сәламәтлек өчен бик куркыныч. Аллергия, астма, ашкайнату системасына зыян килүдән башлап, сукыраюга, хәтта үлемгә китерергә мөмкин, – ди Рөстәм Арсланов.

Зөһрә **САДЫЙКОВА.**

ИСЕРТКЕЧ ЭЧЕМЛЕКЛӘРНЕҢ ЯЛГАНЫН ЧЫНЫННАН НИЧЕК АЕРЫРГА?

Яңа ел бәйрәмнәрендә хастаханәгә эләгәсегез килмәсә, шампан шәрабы һәм башка исерткеч эчемлекләр сайлаганда белгечләр киңәшенә игътибар итсәгез, зыян булмас.

✓ *Исерткеч эчемлекләрне вак-төяк сәүдә нокталарыннан сатып алмагыз. Легаль алкоголь ЕГАИС системасында исәпкә алына. Кассада сканер ярдәмендә аның чынмы-ялганмы икәнлеге ачыклана. Әгәр марка «укылмаса», ул ялган дигәнне аңлата.*

✓ *Шешәнең тышкы кыяфәтенә игътибар итегез. Әгәр бөкесендәге мәгълүматлар (тутырган көне һәм продукциянең алты урынлы уникаль коды) сездә шик уятса, 8-800-550-51-16 телефонына шалтыратып, атаманың код белән тәңгәл килүен тикшертә аласыз.*

✓ *Аракының бәясе. Ярты литр аракының бәясе 190 сумнан да арзанрак булырга тиеш түгел. Ул закон тарафыннан көйләнгән. Әгәр сезгә аракыны бу бәядән арзанракка тәкъдим итәләр икән, шикләнерлек урын бар дигән сүз.*

✓ *Исерткеч эчемлекләрнең составында этил спирты 20 проценттан артып китмәскә тиеш.*

✓ *Әгәр инде шикле сату урыннарына юлыксагыз, бу хакта (843)236-94-11 номерына шалтыратып хәбәр итә аласыз. Закон бозу очраклары расланса, гаепләүләр штрафка тартылачак һәм законсыз эш алып баруда кулланылган әсбаплар алыначак.*

ТОП – 5

ТАТАРСТАН Президенты Рөстәм Миңнеханов республика Дәүләт Советында төбәктә 2015 ел өчен милеккә салым түләмәгән физик затларга пеня түләтә башлау вакытын билгеләү буенча кабул ителгән республика законын имзалады. Искәртеп үтәбез, Татарстанда пеня 2017 елның 1 маеннан салына башлаячак.

2016 ЕЛДА ил халкы, уртача алганда, телевизорны көнгә җиде минутка азрак карый башлаган, ә смартфонда интернетта утыру вакыты, уртача алганда, 18 минутка озынайган, дип хәбәр итә «Татар-информ». Яңалыклар сайтларына һәм рәсми сайтларга Россия халкы телевидениегә караганда күбрәк ышаныч белдерә.

2025 ЕЛГА кадәр Татарстанда мәктәпләр төзелеше буенча кабул ителгән программа нигезендә 38 яңа мәктәп төзү планлаштырыла. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов сүзләренә караганда, мәктәпләрнең 11е иске мәктәпләрне бетерү максатларында төзелсә, калганнары, ягъни 27се икенче сменаны бетерү өчен сафка бастырылачак. Бүгенге көндә республикада балаларның 8-8,5 проценты икенче сменада белем ала. 2020 елга укучыларның 70 меңгә артуы көтелә.

РОССИЯ халкы Яңа ел каникулын Таиланд, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия һәм Европа курортларында үткәрәчәк. Туристлар арасында иң популярлары шулар. Яңа елда ял итүчеләр Европага, экскурсияләргә, тау чаңгысына өстенлек бирә. Туристларның Европа тау чаңгысы курортларына ашкынуы евро курсының тотрыклы, андагы инфраструктураның әйбәт, апартаментларның очсыз булуы, юл бәясе әллә ни кыйммәт булмавы, программаларның күплеге һәм башка уңайлыклар белән аңлатыла.

БӨТЕНРОССИЯ җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләре буенча, респондентларның 76 проценты Яңа елны өйдә каршы алачагын әйткән. 11 проценты – кунакка, 4 проценты – дачага, 2 проценты рестораннга бара. 1 процент кына чит илгә яки пансионатка җыена, 3 процент россияле Яңа елны каршы алырга җыенмый. Яңа елны каршы алу чаралары өчен россиялеләр уртача 12397 сум тотарга җыена. Респондентлар фикеренчә, бүләкләргә 4,338 сум тотарга туры киләчәк, Яңа ел табыны 4164 сумга төшәчәк. Калган чыгымнар чыршы бизәүгә, балаларга кучтәнәч һәм башка максатларда тотылырга мөмкин. Сораштыру 46 төбәкнең 130 торак пунктында үткәрелгән, барлыгы 1600 кеше сораштырылган, дип яза «Татар-информ».

Мандарин бәйрәм кәефен бозмаячак

Интернет челтәрләрдә «мандарин ашап агуланучылар бар, читтән кертелгән мандарин аркасында кискен эчәк инфекциясе тарала» дигән сүзләр йөри. Бу хәбәр күпләрдә шик уятты. Яңа елга мандарин алмыйбыз, диючеләр дә бар.

Мандарин бәйрәм кәефен бозмаячак, ди белгечләр. Россельхознадзор, ветеринария идарәсеннән бер төркем белгечләрдән торган комиссия сәүдә үзәкләрендә, күпләп сату базарларында мандарин сыйфатын тикшерде. Сатудагы мандаринның 70 проценты Кытай һәм Мароккодан керә. Кибет киштәләрендәге юка кабыклы, яшел яфраклары белән бергә сатыла торган вак мандариннар – Кытайдан. Социаль челтәрләрдә нәкъ менә шулар турында сүз бара да инде. Тикшерүчеләр исә лаборатор нәтиҗәләр ярдәмендә мандариннарның кеше сәламәтлеге өчен куркыныч булмавын әйтте. Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат үзәге җитәкчесе Айгөл Сәлимҗанова да: «Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мандарин белән агуланучылар күп дигән мәгълүматны кире кага. Бүген Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсендә мандарин белән агуланган балалар теркәлмәгән. Бу уңайдан «Ашыгыч ярдәм» хезмәтенә дә мөрәҗәгать итүчеләр юк», – диде.

Ничек кенә булмасын, мандарин ашаганда чамасын белергә куша табиблар. Ул аз калорияле, витаминнарга аеруча бай җиләк-җимеш булып санала. Кан басымын нормальләштерә, депрессия вакытында, йөткергәндә файдалы, аппетит булмаганда булыша. Шул ук вакытта, аллергиясе булган кешеләргә, ашказанында җәрәхәт, гастрит, бавыр авырулары вакытында мандарин белән сак булырга кирәк. Табиблар балаларга көненә ике-өч, олыларга биш мандариннан артык ашарга киңәш итми. Мандаринны ашар алдыннан яхшылап юарга кирәклеген дә онытмагыз.

Эльвира **МОЗАФФАР.**

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

2016 ЕЛ: СӨЕНЕЧЛӘР ҺӘМ

Динар Хәмидуллин коллажы

Узып баручы 2016 ел җиңел булмады. Нефтькә бәя төште, рубльнең долларга карата үз позициясен югалтуы әле дә дәвам итә. Һәртөрле сораштырулардан чыгып нәтиҗә ясасак, узып баручы 2016 елның төп вакыйгалары итеп россиялеләр Сүриядәге сугышны, икътисади кризис, бәяләр арту һәм илдәге авыр икътисади вазгыятьне атый. Әмма киләсе 2017 елга халык якты өметләр баглый, 2016 ел белән чагыштырганда, Әтәч елында яхшы хәбәрләрнең күбрәк булачагына өметләнә. Шулай да узып баручы ел россиялеләр һәм татарстанлылар өчен нинди вакыйгалары белән истә калачак соң?

РОССИЯДӘ

ИКЪТИСАД

Россия Президенты Владимир Путин әйтүенчә, быел ил бюджеты «Башнефть»не сатудан һәм «Роснефть»тән 19,5 процент – барысы 1 трлн 100 млрд чамасы акча алды. «Киләчәктә нефть бәясе ун процентка артырга мөмкин. Бу бюджет өчен генә түгел, ә Россиянең Үзәк банкы өчен дә бик файдалы. Аларның максаты – 2017 ел ахырында тотрыклы түбән инфляциягә ирешү. Бу быелгы елда да чиратлап тормышка ашырылды. 2016 ел нәтиҗәләре буенча, инфляция 5,5 процентны тәшкил итә. Бу – елның иң төп казанышы», – дип бәяли икътисад белгечләре. 2015 ел белән чагыштырганда, Россия икътисады быел үсеш кичерде. Моннан кала, алдагы өч елга исәпләнгән бюджетның «кырыслыгы» да уңай үзгәрешләргә өметләндерә.

СӘЯСӘТ

Пальмира шәһәрен террорчылардан азат итте. Майда анда Россия музыкантлары катнашында зур концерт узды. Әмма 11 декабрьдә Пальмираның кабат басып алынуы турында хәбәр ителде. Декабрьдә исә Алеппоның азат ителүе турында мәгълүм булды.

Агымдагы елның төп вакыйгаларының берсе, әлбәттә, сайлаулар. 18 сентябрьдә Россия Дәүләт Думасына һәм төбәк парламентларына сайлауларда «Бердәм Россия» үз позицияләрен ныгытты. Халыкның 47, 88 проценты үз тавышын бирде.

Ел дәвамында халык теленнән төшмәгән тагын бер вакыйга – АКШ Президентын сайлау. Ноябрьдә узган сайлауларда Дональд Трампның җиңүе көтелмәгәнчә булды. Һәм аның 2017-2018 елларда тормышка ашырылачак сайлау алды программасы дөнья икътисады һәм Россия өчен җитди сынау булачак, дип фаразлый белгечләр.

2016 ел Россия белән Төркия арасындагы мөнәсәбәтләр җайлану һәм август ахырында туристларга һава юлы ачылу белән дә истә калачак. Мәскәүдән беренче рейс 2 сентябрьдә очты. Ике ай вакыт эчендә Төркия курортларында 223 меңгә якын россияле ял итте.

19 декабрьдә Төркиядә фотокүргәзмә ачкан вакытта Россия илчесе Андрей Карлов үтерелде.

МӘДӘНИЯТ

10-14 майда Стокгольмда узган «Евровидение»дә Россиядән Сергей Лазарев өченче урын алды. Әберенчегә Украина җырчысы Джамала чыкты. Бәйгенең шарты буенча, 2017 елда әлеге җыр бәйгесе Киевта үткәрелергә тиеш, әмма халыкара җыр бәйгесен оештыру бик күп чыгымнар таләп итә. Шунлыктан «Евровидение» бөтенләй башка илдә, хәтта Россиядә дә узарга мөмкин, дигән сүзләр йөри.

ФАҖИГАЛӘР

19 мартта Дубайдан Ростов-на-Донуга очкан «Боинг 737-800» самолеты һәлакәткә очрады. Әлеге фаҗига 62 пассажирның һәм экипаж әгъзаларының гомерен алып китте. Самолет һәлакәтенә китергән соңгы нәтиҗәләр әле бүгенгә кадәр ачыкланып бетмәгән. Шулай да бу фаҗига пилотның гаебе аркасында килеп чыгарга мөмкин, дип әйтелә.

19 июньдә Карелиянең сәламәтләндерү лагеренда ял иткән 14 бала, су буйлап сәяхәт иткән вакытта көймәләр капланы нәтиҗәсендә, суга батып үлде. Исегезгә төшерәбез, әлеге гадәттән тыш хәл вакытында балалар белән тиешле белемнәре һәм күнекмәләре булмаган практика узучы студентлар эшләгәнлеге ачыкланды. Бу хәлләрдән соң Россиянең барлык балалар лагерьларында да тикшерүләр уздырылды.

4 декабрьдә Ханты-Мансийск округында зур транспорт-юл һәлакәте булды. Ханты-Мансийскидан Нефтеюганскига акробатика ярышыннан кайтып килүче балалар утырган автобус йөк машинасы белән бәрелеште. Әлеге фаҗига 12 кешенең гомерен алды, шуларның унысы – балалар.11 яшь спортчы хәзерге вакытка кадәр реанимациядә дәвалана. Автобус һәм йөк машинасын йөртүчеләргә карата җинаять эшләре кузгатылды.

Россиянең эре шәһәрләрендә яшәүче 1 мең кеше катнашында сораштыру үткәрелгән. 2016 елда иң истә калган вакыйгалар дигән сорауга җаваплар алынгач, түбәндәге нәтиҗәләр ясалган:

- ✓ Илдәге кризис – 40 процент
- ✓ Спортчыларның допинг белән бәйле җәнҗаллары – 21 процент
- ✓ Россия хәрбиләренең Сүриядәге операцияләре – 20 процент
- ✓ Төркия белән мөнәсәбәтләр җайлану – 19 процент

2016 елның декабрь ахыры Иркутскидагы хәлләр белән дә истә калыр, мөгаен. «Боярышник» белән агуланган 120 кеше хастаханәләргә эләкте. Аларның 75е вафат булды. Тикшеренү нәтиҗәләре парфюмер чарасы-

КӨЕНЕЧЛӘР

ның составында агулы метанол кушылганлыгын күрсәтте. Халыкның күпләп агулануы сәбәпле, 12 кеше тоткарланды.

25 декабрьдә халыкара «Адлер» аэропортыннан очкан Ту-154 очкычы, тиешле биеклекне җыя алмыйча, Кара диңгез өстенә төште. Самолет бортындагы тугыз журналист, Александров исемендәге җыр һәм бию ансамбле һәм хәрбиләр – барлыгы 92 кеше һәлак булды.

ҖӘМГЫЯТЬ

Гыйнварда игътибар үзәгендә коллекторлар булды. Ул вакытта банкка бурычын түләүне таләп итеп, коллектор бер йорт эченә яндыргыч сыеклык тутырылган шешәне ыргытты. Нәтиҗәдә 56 яшьлек ир-ат һәм аның ике яшьлек оныгы бик каты пешеп, хастаханәгә эләкте. Җинаятьчене сигез елга төрмәгә утырттылар. Коллекторлар белән бәйле берничә шундый очрактан соң, июльдә аларның эшчәнлеген контрольдә тотучы закон кабул ителде.

19 августта Россия Президенты Владимир Путин мәгариф министры Дмитрий Ливановны эшеннән азат итте. Аны Президент администрациясенең элеккеге түрәсе, яшь вакытта укытучы булып эшләгән Ольга Васильева алыштырды.

9 сентябрьдә Россия Президентының бала хокукы буенча вәкаләтле вәкиле Павел Астахов отставкага китте. Карелиядә булган фаҗигадән соң исән-имин калган балалар белән аралашканда Павел Астаховның алардан: «Ничек йөздегез?» – дип урынсыз сорау бирүе киң җәмәгатьчелекнең нәфрәтен уятты. Аның отставкага китүен таләп иткән петиция кыска вакыт аралыгында дистә меңләгән тавыш җыйды. Аны алты бала әнисе, дин әһеле хатыны Анна Кузнецова алыштырды.

СПОРТ

Июнь-июль айларында Франциядә барган футбол буенча Европа чемпионатының беренче көннәре шау-шулы узды. Урамдагы тәртипсезлекләр аркасында хәтта чараның ачылыш тантанасы да чактан гына күчерелми калды. Футбол буенча Россия җыелма командасы плей-офф уеннарына кадәр барып җитә алмады. Ә чемпионатта Португалия җыелма командасы җиңеп чыкты.

5-21 августта Бразилиянең Рио-де-Жанейро шәһәрендә XXXI җәйге Олимпия уеннары узды. Әмма бу ярышлар да тарихта спортчыларның допинг куллангулары белән бәйле җәнҗаллар, Россия спортчыларын ярышларга «энә күзеннән» уздырулары белән бәйле шау-шулары белән хәтердә калачак. Бик күп каршылыклар аша узган Россия җыелма командасы дүртенче урын алуга ирешә.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Быел авыл хуҗалыгы тармагында зур вакыйга булды – Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбе алынды. Аның тулы нәтиҗәләре 2017 елның IV кварталында гына билгеле булса да, беренче күрсәткечләр турында хәбәр ителде инде. Мәсәлән, Татарстан Республикасында барлыгы 454 мең объект теркәлгән, аларның җир мәйданнары 4189 мең гектарны тәшкил итә.

ТАТАРСТАНДА

– Быел Татарстанда яңа «Аммоний» заводы сафка бастырылып эшли башлады, «ТАНЕКО» предприятиесендә авыр калдыкларны эшкәртү буенча комплекс гамәлгә кертелде. Кече һәм урта бизнестан республика бюджетына 30 миллиард сумга якын акча кертелде. Энергетик системаларны модернизацияләүдә, авыл хуҗалыгы өлкәсендә үсеш күзәтелде. Быел республикада җитештерелгән продукт күләме, узган елдагыга караганда, 2,5 процентка артты. Авыл хуҗалыгында 5,2 процентка үсеш күзәтелә. Россиядә сөт җитештерү буенча без – беренче, ит җитештерүдә – дүртенче, ашлык җыю буенча тугызынчы урынны билибез. Инвестицияләр буенча да алдынгылар рәтендә. Авыл хуҗалыгы буенча – өченче, сәнәгать буенча – дүртенче урында. Нефть тармагы да 4,3 процентка үскән.

– Сәламәтлек саклау өлкәсенә килсәк, быел инфаркт буенча күрсәткечләр 9,5 процентка кимегән. Демография буенча да үсеш бар. Инде менә алтынчы ел рәттән ел саен дөньяга ун меңнән күбрәк бала аваз сала.

– Быел Татарстан мәдәнияте тарихында зур вакыйга булды – «Үзгәреш җиле» музыкаль фестивале булды. Республика Президенты тәкъдиме белән оештырылган фестиваль халыкта төрле фикерләр уятты. Әмма Рөстәм Миңнеханов аның киләсе елга да дәвам иттереләчәге турында хәбәр итте.

– Ел ахырында матбугат чараларында иң күп язылган тема дип, һичшиксез, «Татфондбанк» белән булган вазгыятьне әйтергә кирәк.

«2014 елдагы вазгыять банк системасына нык йогынты ясады. Тотрыклы булмаган банклар катлаулы хәлдә калды. «Татфондбанк» та шулар исәбендә булды. Безнең гаеп юк дип әйтмим. Республикабыздагы хәлләр – безнең гаеп ул. Иллюзияләр белән яшәгәнбездер. «Татфондбанк» өчен борчылдык, әлбәттә. Без хәлне тигезли алырбыз дип өметләндек, әмма вазгыять күпкә катлаулы булып чыкты. Тикшерү дә булды бит. «Татфондбанк»ны тикшергәндә сигналлар булды. Без ачыктан-ачык реаль гамәлләр кирәк дигән идек», – дип белдерде Президент Рөстәм Миңнеханов журналистлар белән Яңа ел алдыннан очрашуында.

– Казанда ноябрьдә 2017 елгы Конфедерацияләр кубогы жирәбәсе узды. Нәтиҗәдә төркемнәр түбәндәгечә формалашты: «А» төркемендә: Россия, Яңа Зеландия, Португалия һәм Мексика уйнаячак. «В» төркеменә Африка, Чили, Австралия, Германия эләкте. Ачылыш матчы 17 июнь көнне Санкт-Петербургта узачак. Россиялеләр Яңа Зеландия командасы белән очрашачак. Ә Казанда беренче уен 18 июнь көнне була. Биредә Португалия һәм Мексика җыелмалары очрашачак.

Моннан кала, Казанда бадминтон, самбо һәм дзюдо буенча Россия чемпионаты һәм җиңел атлетика буенча Россия чемпионаты узды.

rbc.ru

Узып баручы ел тормышыгызга нинди яңалыклар алып килде?

Индус ТАҺИРОВ, ***тарих фәннәре докторы, сәясәтче, Татарстан Фәннәр академиясе академигы:***

– Быел үземнең 80 яшемне бик зурлап билгеләп үттек. Республика дәрәҗәсендә дә, институтта да зур хөрмәт күрсәттеләр. Шушы уңайдан китапларым чыкты. Аның берсе Мәскәүдә бастырылды. Китапның беренчесе татар телендә булса, икенчесе татар, рус һәм инглиз телләрендә дөнья күрде. Аннан соң башка бик күп вак-төяк мәкаләләрем, фәнни хезмәтләрем чыгып торды. Уку-укыту эшләре белән дә шөгыльләндем. Аллага шөкер, балалар белән дә, гаиләдә дә барысы да яхшы. Ил, милләт язмышы гына борчый. АКШ сайлауларының нәтиҗәсе белән бәйле илдәге билгесезлек тынгылык бирми. Татарстан Россия төбәкләре арасында беренчеләр рәтендә тора. Дөньякүләмендә барган шушы үзгәрешләр киләчәктә безгә ни рәвешле кагылыр икән? Әнә шул турыда уйланам. Шунысы сөендерә, Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Россия хөкүмәтенә, республикадан тиеш булмаган акчаларның читкә китүе турында җиткерде. Бу – зур батырлык. Шушы ук фикерне Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин дә куәтләде. «Һәр төбәк үз көнен үзе күрергә тиеш. Без аларга балык түгел, ә кармак бирик», – диде ул. Бу – Россия өчен зур проблема, әлбәттә, әмма аны чишү дә бик авыр.

Вилдан ГАРИПОВ, ***100 яшь, Лаеш районының Имәнкискә авылы:***

– Быел миңа 1 июльдә 100 яшь тулды. Бик күп котлаулар кабул иттем. Район башлыгы Михаил Афанасьев та, Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин да килеп тәбрикләделәр. Президентыбыз да килергә тиеш иде, тик килеп кенә җитә алмады. Шулай булса да башка кешеләр артыннан котлавын да, бүләккә дип диванын да җибәрде. Туган көн Рамазан аена туры килгәнлектән, киленем ул көнне авыз ачтырды. Аллага шөкер, күзләрем күрә, зиһенем дә бик яхшы, тамагымнан ризык та үтә. Балаларым үземне күтәреп кенә йөртә. Киленемне безнең бәхеткә Ходай биргән, дим. Тик менә күңелне борчып торган бер генә мәсьәлә бар. Авылыбызның клубы авария хәлендә, бик иске, шунлыктан концертлар да куелмый. Чөнки аңа керә торган түгел – куркыныч. Авылда кафе бар, ә мәдәният йорты юк. Бу хакта Президентыбызга да җиткердем. «Мин үзем гармунда уйныйм, аяны тәзетсәгез, шунда чыгып сыздырыр идем», – дидем. Ул өч ай эчендә төзеп бирергә вәгъдә итте. Менә хәзер шуны көтәбез инде.

Рамазан САДЫЙКОВ, ***5 яшь:***

– Мин хәзер хәрефләр, саннар танырга өйрәнәм, бераз укыйм да. Җәй көне футбол уйный башладым, ике тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәндем. Миңа ошый. Лего төзергә дә яратам. Аннан әллә нәрсәләр ясап бетерәм! Бу Яңа елда Кыш бабайдан мультиктагы кебек робот сорадым. Теге юлы ул тимераяк алып килгән иде, шуннан соң бозда шуарга өйрәндем. Кыш бабай әниләрен тыңлаган, аларга булышкан, уенчыкларын җыештырган малайларга гына бүләк алып килә. Без аңа сеңлем белән хат язып, чыршыга элеп куйган идек, йокыдан торуга алып киткән. Димәк, ул безгә бүләкләр алып киләчәк инде.

Мансур ТӨХФӘТУЛЛОВ, ***Буа районының Яңа Тинчәле авылы җирле идарә башлыгы:***

– Быел авылыбызга бер чакрым юл салынды, мәктәп һәм мәдәният йорты төзекләндерелде. Элеккеге чорда монда 700 йорт булган, хәзерге көндә 300 хуҗалык исәпләнә. Дүрт шәхси кибет, ике мәчет эшли. Авыл халкы бик тырыш. Авылыбызда гына да сигез фермер гаиләсе бар. Унбиш баш сыер асраучылар да бар хәтта. Быел да күрсәткечләребезне киметмәдек. Мөгезле эре терлек, сарыкларны да арттырдык. Быел кош-корт асраучылар күбәйде. Меңәр баш алучылар да бар. Аларны үстереп саталар. Кешеләр шушы шәхси хуҗалыкларда яки фермада эшли. Болардан тыш, авыл тарихына багышланган «Бертуган Бикколовлар» китабы чыкты. Аны бик зурлап билгеләп үттек – тәкъдир итү кичәсе оештырдык.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде.

Яңа елда бергә булыйк

Гадәттә эшләнгән эшләргә ел азагында йомгак ясала. Бу көннәрдә редакциябез тагын да җанланды. Укучыларыбыз еллык эшебезгә бәя бирә, котлауларын җиткерә, рәхмәт сүзләрен әйтә.

Эльвира МОЗАФФАР

Әле шушы көннәрдә генә актив укучыбыз Миңлегөл Әдһәмова килеп китте. «Юлларда күп йөрисез, һәр сорауны ачыклыйсыз, күз тимәсен үзегезгә, яман күзләрдән саклар өчен дога алып киләм әле», – дип тә вәгъдә итте. Равилә Мөбарәкшина Яңа ел табынын бизәү өчен киңәшләр тупланган берничә төсле журнал, рецептлар тупланган җыентыклар бүләк итте.

Тынычлык бистәсендә яшәүче тынгысыз укучыбыз Ильяс Мөхәммәтшин исә, гадәттәгечә, безгә «тема тапкан». «Бездә җәяүле чыга торган бер урын бар, шунда машиналар тукталмый, җәяүлене уздырмый. Килегез әле, фотограф та кирәк монда, светофор төбенә утырабыз да, тәртип бозучыларны фотога төшереп барабыз. Бу эшне ЮХИДИ хезмәткәрләре генә башкарып чыга алмый, «Шәһри Казан» кирәк», – ди ул.

Танылган аш-су остасы Юныс Әхмәтҗановның сеңлесе Гамбәрия апа Гафурова газетабызны 25 елдан артык алдыра. «Һәр язманы укып барам, кайсыларын кат-кат укыйм, җыеп та куям әле. «Шәһри Казан»ны сагынып көтеп алам», – ди ул.

Гамбәрия апа редакциягә, үзе яшәгән йортның подъездларына ремонт ясамыйлар, кунак килсә дә оят, дип зарланып шалтыраткан иде. «Шәһри Казан» газетасы инициативасы белән, бу мәсьәлә уңай хәл ителде. Хәзер подъездлар ялт-якты, чиста. Гамбәрия апа исә шатлыктан редакциябезне кунакка чакырды.

Әхмәтҗановлар биш бала үссәләр дә, Гамбәрия апа бүген үзе генә исән. Ул – сугыш ветераны. Ире Габделхак абый белән яшиләр. Кызлары Наилә, уллары Наил – төп терәкләре. 88 яшендә булса да, Гамбәрия апа тик тормый, күз тимәсен үзенә. Безне дә абыйсы Юныс Әхмәтҗанов рецепты буенча пәхләвә әзерләп каршы алды.



– Безне аш-суга әниебез Зәйнәп өйрәтте. Ул бик оста пешекче иде, – ди Гамбәрия апа.

Юныс абый исә әнисенең нәрсәне ничек пешергәнен дәфтәргә теркәп бара торган булган. «Татар халык ашлары» китабының беренчесендә дә нәкъ менә әнисенең рецептлары урын алган. Аннан Юныс Әхмәтҗанов, төрле авылларга барып, оста пешерүчеләр белән күрешкән, иң борынгы рецептларны да эзләп тапкан. Шуңа да аның рецептлары буенча пешерелгән ризыклар үзенә бер төрле тәмле, үзгә. 2017 елда Юныс Әхмәтҗановның тууына 90 ел була икән. Шагыйрь Роберт Миңнуллин бу уңайдан данлыклы аш-су остасы турында китап та яза.

Юныс Әхмәтҗанов пәхләвәләрен кайчан авыз итеп караган булыр идек, телеңне йотарлык күчтәнәчегез өчен рәхмәт сезгә, Гамбәрия апа.

«Шәһри Казан» газетасыннан аерылмаган, шатлыкларын, борчуларын безнең белән уртаклашкан, тәкъдимнәрен, фикерләрен җиткереп торган укучыларыбызга зур рәхмәт. Без сезне тыңларга, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә һәрчак әзер. Яңа елда да бергә булыйк!

Әле генә исән идең, апа...

Узган ел сәгать телләре уникегә якынлашып, Яңа ел җитеп килгәндә, әниемнең сеңлесе Шәмсинур апа да исән иде әле. Һәр елдагыча, 2016 елны да «Һәрбарчабызга исән-имин яшәргә язсын!» – дип, догалар укып каршы алган иде. Ләкин, нишләптер, алар кабул булмады. Апабызның гомере чәчәкле җәй көнендә, дөресрәге, төнендә явыз адәм кулыннан өзелде. (Бу хакта «ШК»ның 4 август санында язган идек.)

Буаны гына түгел, бөтен Татарстанны шаулатты апаның үлеме. Тыныч кына гомер йомгагының соңгы сапламнарын сүтеп яткан сиксәнгә җитеп килүче бер гаепсез карчыкны үз өенә кереп үтереп чыктылар. Ата – улны, ана кызны белми торган зур шәһәрдә булса бер хәл, Буа зур авыл бит инде ул. Аяз көнне яшен суккандай, бу хәбәр бик күп ялгыз карт-карчыкларның тынычлыгын алды: ишек-тәрәзәләренә бик салды. Җинаятьчене эзләү эшенә Казан тикшерүчеләре дә кушылды. Чөнки җинаятьче эзен бик нык яшергән, алдан ук әзерләнеп, кулына пирчәткә киеп эшләгәнгә, бернинди «телсез шаһитлар» да калдырмаган иде. Ләкин без капчыкта ятмый. Буа бит ул, анда берсен-берсе белүче халык яши. Бер егетнең кичке якта апа йорты янында киләп сарып йөрүен күреп калучылар булган. Кибеттәге видеокамера да шушы егетнең акча ваклап, товар алганын үзенең хәтеренә язып калдырган. Канлы эшен төн карасында башкарган, үзе әйтүенчә, 900 сум гына акча таба алган бу адәм актыгы өенә кайтып, башта йокыга талган, бик арыган булган, күрәсең. Аннары йокысыннан уянгач, тотылудан куркыптыр инде, элек яшәгән Краснодар якларына китеп барган. Үзенең гомере җәл, кешенеке генә бер тиен дә тормый шул ул андый ерткычларга. Ләкин ерак китә алмаган. Апамның җидесен уздырган көннәрдә аны богаулап алып та кайтканнар. Августтан ноябрь башына кадәр өч ай буе тикшерү эшләре барды. Шаһитлардан сорау алынды, апамның улы Илдарның да йөрәк яраларын яңартып, каткат сораштылар. Әнисенең үле гәүдәсен ул иң беренче күргән кеше.

Һәм менә хөкем көне дә килеп җитте. Җинаять гадәттән тыш авыр дип табылгангадыр инде, хөкем утырышлары да районда түгел, ә Казанда Югары суд бинасында берничә көн буе барды. Беренче утырышында мин дә катнаштым, башка туганнарыбыз да, апаларының әҗәле булган бу вәхшине үз күзләре белән күрергә теләп, күрше шәһәрләрдән дә килделәр. Җинаятьче егетнең дә якыннары залда иде. Әнисе бигрәк кызганыч тоелды. Иртә тол калып, тормыш дилбегәсен ялгызы тартып, ике бала үстергән бу ханым чынлап та бик җәл иде. Бер генә әни дә: «Балам, үтер, җинаять кыл!» – дип үстерми бит инде газизен. Үзенә сүз биргәч тә ул: «Улымның җинаятьче булуына һич кенә дә ышана алмыйм, ул бик нечкә күңелле бала», – диде. Монысы да аңлашыла. Бер генә әни дә балам үтерүче дими бит инде, ни энәле керпе дә баласына «йомшагым» дип әйтә, ди. Хөкем утырышында Әниләр көне алдыннан узуы бу ана фаҗигасен тагын да тирәнәйтте. Белгәннәребезне укып: «Ходаем, күрсәтмә, хагыннан нахагыннан үзең сакла!» – дип телән утырдык.

Әнисе ышанмыйм дисә дә, улы Ленар Садриев җинаятен таныды. Ул үтерергә дип түгел, муеннан бурычка баткач, бу карчыкта үлемтеккә дигән акча булса да бардыр әле диптер инде, караклык юлына баскан, төн берендә коридор тәрәзәсен алып, ярдәмчесез карчык өенә кергән. Ләкин кирәк була калса дип, кулына юан гына агач таяк алырга да онытмаган. Һәм аның кирәге чыгуы бик кызганыч. Өендә чит кешенең аяк тавышларына уянган апам ни булганны да аңламыйча, инстинкт буенча, каракны кулыннанмы – аягыннанмы тоткан. Җинаятенең шаһиты булудан, үзен күреп калуларыннан курыккан карак (ә карак ул гел куркак була, аны үз шәүләсеннән дә курка дип юкка гына әйтмиләр бит инде) кулындагы көсәк белән апамның башына, кулларына дистәдән артык тапкыр суккан. Болай да җаны нечкә кылда гына эленеп торган, гомере буе сау көнгә туймаган карчыкка күп кирәкмени инде. Ул беренче сугудан ук җан биргән ди судмедэкспертиза. Көсәк аннан апамның җансыз гәүдәсен тукмаган булып чыга...

Утызны яңа гына тутырган бу егет. Апаның олы оныгы белән бер яшьтә. Бер мәктәптә укып, бер урамда уйнап үскән малай. Балачакта бу йортка кергәне дә булгандыр әле, апам аны бакчасында үскән алма-чия яки үзе пешергән берәр тәмле әйбер белән дә сыйлаган булгандыр.

«Мин ул төнне эчкән идем, берни дә хәтерләмим», – дисә дә, бу аклану җәза катылыгын киметә алмады. Ике атна барган суд утырышыннан соң хөкем карары яңгырады: «Җинаятьчене кырыс режимлы колониядә 14 елга ирегеннән мәхрүм итәргә». Исәнсау булып кайта алса, ирекә чыкканда аңа 45 яшь булыр. Әрәмгә узган гомер була инде ул. Тик апамны гына берничек тә күпме еллардан соң да кайтарып булмас инде, бик газаплы үлем белән кеше кулларыннан китәргә язган булган шул мескенкәйгә..

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Студентларның сәламәтлеге сагында

Мәктәптән соң баласын чит шәһәргә укырга җибәргән ата-ананың борчылуын аңлау кыен түгел. Баланы бер белмәгән җиргә япа-ялгызын чыгарып җибәрдем дип бер борчылса, улы яки кызы авырый башласа, тагын тынгылыгын җуя алар. Универсиада авылында урнашкан 4нче шәһәр студентлар сырхауханәсендә булганнан соң, Казанда укучы студентларның сәламәтлеге уңаеннан борчылып ятарга кирәкмидер дә дигән нәтиҗәгә килдем. Чын-чынлап ышанычлы кулларда алар. Мондый заманча, иркен (6 мең кв метр мәйданны биләгән дүрт катлы бина!) сырхауханә башкаларның түшенә дә кергәне юктыр әле.

Расиха ФӘИЗОВА

Регистратурада студент Булат Мортазин белән аралашып алабыз.

– Монда студентлар гына булгач, башка сырхауханәләрдәге кебек зур чиратлар юк. Бу бик яхшы. Шәхсән үземнең инде өч еллап авырганым да юк, – ди егет.

тына, 38 урта профессиональ белем бирү учреждениесенә хезмәт күрсәтә әлеге үзәк. Көн саен медицина ярдәме сорап 1200 студент мөрәҗәгать итсә, бу сан елына 270 меңгә җитә икән.

Автор фотолары

КАЙДА ДА ҖИТЕШӘЛӘР

Үзәкнең баш табибы медицина фәннәре кандидаты Айрат Зыятдинов белән

Безнең белгечләр Мәскәүгә, Петербургка, Германиягә, Австриягә кадәр барып укып, өйрәнеп кайттылар. Пациентларга хезмәт күрсәтү стандартлары хакында әйдәп баручы клиникаларның әйдәр белгечләре килеп тә укытты, – ди Айрат Зыятдинов.

КЛИНИКА – ҮЗЕ БЕР ТӘҖРИБӘ БАЗАСЫ

Әлеге үзәк медицина юнәлешендә белем алучы студентларга үзенчәлекле тәҗрибә базасы булып та тора. Бирегә Казан дәүләт медицина академиясенең, Казан дәүләт медицина университетының кафедралары бар. Шуңа да үзәк коридорларында ак халатлы студентларны очрату гадәти күренеш. Ординатура, интернатура узучылар да бар биредә.

Ә бүген нәрсә борчый соң, дип сораганымны сизми дә калдым. «Военкомат», – ди ул, көрсенеп. Ә менә Анголадан килгән I курс студенты Клавдия башы авыртудан зарланып алды. Табибларга беренче генә килүе түгел икән. Киләчәктә инглиз теле укытачак Максат Попыевның да (КТТУ) ике-өч көн инде медбелешмә тутыртып йөрүе.

2013 елда, Универсиада концепциясе кысаларында, спортчыларга, Студентлар спорты халыкара федерациясенә, аларның гаиләләренә, спорт чарасына аккредитацияләнгән затларга медицина хезмәте күрсәтү максатын күздә тотып төзелгән әлеге медицина үзәге – бүген шәһәр студентлары карамагында. Медицина тикшерүен тулысынча үткәрергә ярдәм итә торган заманча аппаратура белән җиһазландырылган үзәкнең өстенлеге бәхәссез. Һәм әйтергә кирәк, Универсиада мирасы лаеклы хезмәт итә. Шул ук вакытта биредә дәвалау белән генә шөгыльләнмичә, профилактикага да зур игътибар бирелә. Елына 38 мең (!) студентка профилактик медосмотр уздыру – бу инде уен эш түгел. Студент медосмотр узды да онытты түгел, аларны диспансер учетына куялар. Авырулары ачыкланганнарны алга таба тар белгечләргә–табибларга яздыралар. Кичектергесез ярдәм кирәк булганда, табибны тулай торакка чакыртырга да мөмкин. Җәмгысы республиканың 30лап югары уку йортында (рәсемдә) алар колачлаган эшләр хакында шактый сөйләштек.

– Үзәкнең филиалы югары технологияләр шәһәре – Иннополиста да бар. Без Республика клиник сырхауханәсе белән берлектә анда яшәүчеләргә дә медицина ярдәме күрсәтәбез. Универсиада авылында урнашкан IT-лицей да безнең карамакта. Шул ук вакытта эре вузларда 10 филиалыбыз эшләп килә. Коллектив зур, бердәм. 207 кешенең 76сы – табиб, 66сы –урта медицина персоналы. Студентларның сәламәтлеген кайгырту өстенә, Универсиада, ФИНА кебек эре халыкара чараларда беренчел санитар-медицина ярдәме күрсәтеп киләбез. Конфедерация кубогында да катнашабыз. Конфедерация кубогына җирәбә салу вакытында волонтерлар өчен җавап бирдек. Чиратта – Футбол буенча дөнья чемпионаты. Эшче һөнәрләре буенча «WorldSkills-2019» халыкара чемпионатында да медицина ярдәме күрсәтәчәкбез, – ди баш табиб.

Республиканың 30лап югары уку йортына, 38 урта профессиональ белем бирү учреждениесенә хезмәт күрсәтә әлеге үзәк. Көн саен медицина ярдәме сорап 1200 студент мөрәҗәгать итсә, бу сан елына 270 меңгә җитә.

Үзәктә 48 төр медицина ярдәме күрсәтелүе, киңәйтелгән физиотерапия бүлеге турында да горурланып сөйли ул. Чөнки чемпионатлар вакытында спортчылар алган травмалар иң күп очракта физиотерапия дәвалавы таләп итә, ди. Икенче урында стоматология тора икән.

– Безнең студентлар бер үк вакытта төрле спорт командалары составына кергәнлектән, ярышлар, зур тренировкалар алдыннан да, күнегүләр вакытында һәм соңыннан да медицина тикшерүе уздырабыз. Универсиада вакытында безнең тикшерүләр нигезендә спортчыларның йөрәккан тамырлары системасы эшчәнлегенең дөнья стандартлары да эшләнде. Универсиада вакытында республиканың барлык медицина учреждениеләре бик югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтте, чөнки әзерлек эшләре күпкә алдан башланган иде. Хезмәт күрсәтүгә кагыламы ул яки башка мәсьәләгәме — һәммәсе мөһим.

– Бу звено бик мөһим. Чөнки нәкъ менә практика вакытында студентлар киләчәктә нинди юнәлеш буенча китәчәкләрен аңлыйлар. Бездә ел саен Казан дәүләт медицина университетыннан – 560, академиядән 300ләп студент практика уза. Әле бит соңыннан кемнәрдер биредә стоматология, физиотерапия, гинекология булекләрендә эшкә дә төпләнеп кала, – диләр җитәкчеләр.

Сырхауханәдә бер үк вакытта көндезге стационар да эшли. Дәвалану бушлай.

– Студентларда иң еш күзәтелә торган проблема, ул – нагрузканың күбәюе, вакытында ашамыйча ачлы-туклы йөрү, иммунитетның түбән булуы. Аннан мәктәптә укыганда медицина күзәтүләренә җиңел карау аркасында калкып чыккан проблемалар да шактый очрый, – ди гинекология булеге мөдире Светлана Шакирова.

Яшьләр белән турыдан-туры эшләүче үзәк буларак, әлбәттә, биредә заманча программалар актив кулланышта. Әйтик, табиблар белән социаль челтәрләрдә аралашу бик популяр. Мөрәҗәгатьләрнең 80 процентка якыны аралашу вакытында ук хәл ителә, диләр. Аноним кабул итуләрнең нәтиҗәсе дә бәхәссез. Әлеге программа кысаларында, җиде меңгә якын студент тиешле ярдәм алган.



Әтәч менде читәнгә

2017 ел кытай календаре буенча Кызыл Утлы Әтәч елы. Әтәч – Кояш символы, иртән-иртүк торып, үзенең җыры белән йокыдан уята. Шуңа да Көнчыгыш илләрендә әтәчтә кояш энергиясен күрәләр. Әтәч елы безгә нәрсәләр алып киләчәк? Йолдызлар бу җәһәттән ниләр сөйли? Карап карыйк!

КУЧКАР

Алдагы ике еллары «тормыш ул – көрәш» девизы астында узган кучкарлар өчен, ниһаять, тыныч вакыт килә. Ел аларга тормыш рәхәтлекләре вәгъдә итә, ягъни мәсәлән, тормышларында чып-чын «курорт» этабы башлана. Кучкарлар бик күп кызыклы кешеләр белән танышачак. Шәхси тормышта үзгәрешләр июль аенда көтелә. Бу бигрәк тә ялгызлар өчен уңышлы чор булачак. Финанс мәсьәләсенә килгәндә, акчаны ничек эшләргә дигән сорау аларны бөтенләй борчымас кебек. Үз эшләрен ачарга теләүчеләр 2017 елда тәвәккәлләп карый ала. Йолдызлар августны да иң уңышлы ай дип атый.

ҮГЕЗБОЗАУ

Нинди генә эшкә алынсалар да, нәтиҗәсе үзләре көткәннән дә яхшырак булачак. Өстәмә белем алучылар аның әҗерен дә күрер. Кайберәүләрнең яшерен сәләтләре ачылып, эшчәнлек төрен дә алыштырырга мөмкиннәр. Йолдызлар үгезбозауларга гаилә коруны кичектермәскә куша. Ялгызлар булачак тормыш иптәшләрен өйдән читтә очратачак. Шуңа да сәяхәткә чыгарга, командировкага барырга мөмкинлек тууга, моны кулдан ычкындырмагыз. Быел үгезбозауларга кирәкле вакытта кирәкле урында булырга һәм берданбер дөрес карарны кабул итә белергә кирәк. Шулай булганда, акчага мохтаҗлык күрмәссез.

ИГЕЗӘКЛӘР

Әтәч елында игезәкләр бөтен нәрсәдә дә тылсым күрәчәк. Бу ел сезне яңа тәэсирләр белән сөендерәчәк. Кайберәүләрдә хәтта әлегә кадәр сизелмәгән алдан күрүчәнлек барлыкка киләчәк. Иң мөһиме – эчке сиземләүгә ышанырга кирәк һәм барысы да әйбәт булачак. Буйдаклар, ниһаять, тормыш кору турында уйлый башлар. Йолдызлар бәхәсләр туган очракта тыныч һәм сабыр булырга киңәш итә. Ел башында акчаны шактый сарыф итәргә туры киләчәк. Бу фатир яки башка милек төре сатып алу белән бәйле. Бурычка акча алып, каешны ныграк та кысарга туры киләчәк. Ә менә сәламәт яшәү рәвеше алып баручыларга сәламәтлекләренә зарланырга сәбәп юк. Алар хәтта үзләрендә Эверест тавына менәрлек көч сизәчәк.

КЫСЛА

Кыслаларның эчке дөньясын «үзгәртеп корулар» көтә. Алар бөтен иске нәрсәләрдән котылып, тормышларына яңалык кертергә омтылачак. Әлеге үзгәрешләр тормышларының бөтен өлкәсендә дә чагылыш таба. Яңа танышларыгыз шәхес буларак үсәргә ярдәм итә. Ялгыз кыслалар тәвәккәлрәк булсын. Танышулар өчен яз айлары кулай. Ә менә эш урынын алыштырырга ашыкмагыз. Киресенчә, булган эшегездә үзегезнең нәрсәгә сәләтле булуыгызны ныклап күрсәтергә тырышыгыз, хуҗагыз бәяләми калмас. 2017 елда ерак яшәүче, сирәк аралаша торган туганнар белән күрешү җае чыгачак.

АРЫСЛАН

Горур һәм мөстәкыйль арысланнар гадәти булмаган хәл алдында калачак. Бернинди тырышлык күрсәтмичә генә дә күп нәрсәгә ирешәчәксез. Февраль аенда эшнең сыйфатын арттыру буенча кызыклы гына идеяләрегез туар, шуның белән җитәкчегез алдында абруегыз артыр. Хезмәт хакы артуын һәм карьера баскычыннан йөгереп менеп китүне сизми дә калырсыз. Ике куян артыннан куып, берсен дә тота алмаучылар бар. Бу гыйбарәне арысланнарга истән чыгарырга ярамый. Ә менә шәхси тормышка килгәндә, Әтәч аның сценариесен төзеп куйган инде. Ялгызлар туй вальсын өйрәнә торсалар да була.

КЫЗ

Әтәч елында кул кушырып кына утырып булмас. Мөстәкыйльлек яраткан кешеләр эшнең күплегеннән курыкмас, ә менә агымга ияреп йөрүчеләргә яхшы гына тирләргә туры килер. Бу елда, бигрәк тә яз айларында бәхетле билет отарга мөмкинсез. Берничә лотерея билеты алып кую комачауламас. Шәхси тормышларына яңалык кертергә теләүчеләргә, паспортка штамп куярганы-юкмы дип шикләнүчеләргә ноябрь аеннан да соңга калмаска кирәк. Әтәчне исә туйга тамада итеп чакырырга онытмагыз. Хезмәттәшләре белән мөнәсәбәтләре киеренке булганнар элемтәләрне яңарту өстендә эшләсен.

ҮЛЧӘҮ

Ике сүз белән генә әйткәндә, зур мөмкинлекләр елы. 2017 елда булачак уңышларыгыз фәкать үзегездән генә тора. Сезгә бу очракта эшләргә, эшләргә һәм тагын бер кат эшләргә дип кенә телисе кала. Матди яктан узган Маймыл елы сезне бер дә рәнҗетмәде. Әтәч тә традицияне бозмаска вәгъдә итә. Акчагызны тегендә-монда сарыф итмәгез, ә менә хәйриячелек белән шөгыльләнү тәкъдиме бар. Иҗади кешеләрнең хоббилары өстәмә акча эшләү мөмкинлеге бирәчәк. Ялгызлар элеккеге мәхәббәтләрен очратачак, әмма бер киселгән икмәк кире ябышмый. Мәхәббәткә сусадым дип, беренче очраган кешенең кочагына да атылырга кирәкми.

ЧАЯН

Зур үзгәрешләр алдында торасыз. Кыюларны ул үзгәрешләр сөендерәчәк, ә кыюсызлар исә куркып калачак. Алда нәрсә буласы бары үзегездән тора. Йолдызлар тәвәккәл булырга, үзегез өчен яңа дөнья ачарга чакыра. Бу сезнең якыннарыгызга да ошамаска мөмкин, әмма сездәге үзгәрешне күреп, алар һичшиксез тынычланыр. Әтәч чаяннарга күңелле очрашулар, кызыклы танышулар әзерләгән. Эшләрен алыштырырга теләүчеләргә җайне көтәргә кирәк. Балык тозлаучы буласызмы, сыра кайнатачаксызмы – сезне һәркайда уңыш көтә. Ноябрь аенда исә көндәшләрегез баш калкытачак, әмма чаяннар «власть» өчен көрәшергә һәрчак әзер.

УКЧЫ

Көчле энергетикага ия укчылар быел үзләрен бик бәхетле сизәр. Булган проблемаларны чикләвек ваткан кебек бик тиз чишәр. Моның өчен нервыларын да, вакытларын да әрәм итмәсләр. Йолдызлар бер елгага ике тапкыр керүдән курыкмаска киңәш итә. Күптән аралашмый торган, кайчандыр хәтерегезне калдырган дусларыгыз белән элемтәләрне яңартып карагыз. Нәтиҗәдә сез үзегезне яңа яктан ачып, кызыклы идеяләр белән янып яши башларсыз. Ә менә карьера баскычыннан күтәрелү турында уйларга иртәрәк, аның өчен кулай вакыт түгел, югыйсә ярык тагарак алдында калуыгыз бар.

КӘҖӘМӨГЕЗ

Яшереп торырга кирәкми, кәҗәмөгезләрне катлаулы ел көтә. Адым саен каршылыкларга очрап, язмышка үпкә дә белдереп алырсыз. Әмма иң элек үз өстегездә эшләргә, камилләшергә кирәк. Дөньяга яңача карый башлагач, әйләнә-тирәдәгеләр дә үзгәреп киткәндәй булыр. Принципларыгыздан арынгыз, югыйсә буш урында үзегезгә проблемалар гына табып торасыз. Яз уртасында Әтәч сезгә сюрпризлар әзерләп куйган. Бу иң беренче чиратта финанслар белән бәйле. Акча ишелеп кермәсә дә, акча янчыгыгыз һәрчак тулы торыр.

СУКОЯР

2017 ел чын мәгънәсендә Сукоярлар елы. Нинди генә бәхәскә кергән очракта да, алар һәрчак үзләренең дөреслекләрен раслый алачак (чынлыкта хаклы да булмаска мөмкиннәр). Февраль аенда һөнәр алыштыруыгыз ихтимал, мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз. Үзләрен иҗатта сынап караучылар өчен дә кулай вакыт. Карандаш, буяулар, ручка, кәгазьләр әзерләп куегыз. Сез язган поэмаларны безгә дә укырга туры килмәгәе. Күзен төзелеш материаллары сатыла торган кибетләрдә еш кунак булачаксыз. Бөтен вакытыгызны торак шартларын яхшыртуга багышларсыз. Дизайнерлар чакырырга кирәкми, ул эшне үзегез дә шәп башкарасыз.

БАЛЫК

Берничә елга сузылган «торгынлык» елы тәмам. Сезнең тормышыгызда яңа этап башлана, чын мәгънәсендә бәхет диңгезендә йөзәрсез. Карьерада зур сикереш ясарсыз. Энергиягез ташып тора, яңа идеяләр туып тора. Әйләнә-тирәдәгеләр сезне бөтенләй «танымаска» мөмкин. Шәхси тормыш турында да ныклап уйлый башларсыз. Күпләр чын мәхәббәтләрен табып, гаилә дә корып куяр. Аерылышкан парлар яңадан кушылып куярга мөмкин, моның өчен беренче адымны сезгә ясарга кирәк. Төпле эше булмаганнарга йолдызлар эшне язын эзләргә куша, уңыш елмаймый калмас.

Экстрасенс Алсу Газыймҗанова:

«2017 ел җиңелрәк булачак»

«Экстрасенслар көрәше» проекты аша күпләргә таныш Алсу Газыймҗанова былтыр, «Шәһри Казан» редакциясенә килеп, 2016 елга фаразларын әйткән иде. Ни хикмәт, сөйләгәннәрнең шактые чынга ашты. Алсу әйткәннәрне бергәләп искә төшерик әле.

«2016 елда Көнбатышта җир тетрәүләр, бик күп су күрәм. Табигать бәла-казалары кичергән илләр Россия турында онытып торачак».

Шөкер, быел безнең илдә җәй гарасатларсыз узып китте. Яз көне кар күп булу сәбәпле, халык су басулар булыр дип сагайса да, Алланың рәхмәте, бар да тыныч узды. Ә менә Көнбатыш илләрендә табигать бәла-казалары аркасында шактый зыян күрүчеләр чынлап та булды.

Март аенда Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә узган көчле штормны күпләр хәтерлидер. «Дубай су астына китте» дип тә язды бу куркыныч вакыйга турында матбугат чаралары. Социаль челтәрләрдәге, телевизор экраннарындагы кадрларны күреп, чынлап та куркырлык иде шул: машиналар – су астында, көчле җил агачларны тамыры белән каерып ата, һавада реклама элмә такталары оча.

Май аенда Шри-Ланканы су басты. Бәла-каза нәтиҗәсендә 100дән артык кеше һәлак булган, йортлар җимерелгән, илнең икътисадына 2 миллиард доллар зыян килгән, дип сөйләделәр.

Чилида, Мексиканың көнбатыш яры буенда җир тетрәде, Италиядә 6 баллы җир тетрәү 14 кешенең гомерен өзде.

«Никтер күз алдына Германия килеп баса. Аның безгә нинди катнашы бардыр, мөгаен, безнең яклы булыр».

Алсуның фаразларын без быел ачылган Казан – Франкфурт-на-Майне – Казан рейсы, Татарстан Президентының Германиягә барып уртак бизнес турында сөйләшүләре белән бәйләп карадык. Аралар чынлап та якынайды бит. Казаннан Франкфуртка 4 сәгатьтә барып җитеп була. Икътисад өлкәсендә дә Германия белән Татарстан арасында элемтәләр ныгый бара. Республикабызда Германия инвестицияләре катнашында 80 предприятие эшли. Рөстәм Миңнеханов үзе дә быел Дрезден шәһәрендә инновацияле сәнәгать компанияләре эшчәнлеге белән танышып кайтты. Германиядәге татарлар белән дә очрашты.

«Ә менә Россиянең Белоруссия белән аралары суына».

Белоруссия Республикасы Президенты Александр Лукашенконың «Белоруссия һәм Россия мөнәсәбәтләрендә проблемалар шактый» диюен шуңа юрарга мы икән? Газ буенча бәяләрне килешүдә, нефть җибәрү мәсьәләсендә каршылыклар, илләр арасындагы товар әйләнешенең кимүен исәпкә алсаң, чынлап та, ике республика арасында аралар артык җылы түгел кебек.

«Татарстанда һава торышының тотрыксыз килүе көтелә» дигән фаразын соңгы берничә елга карата да әйтергә булыр иде.

Табигать күренешләре, соңгы арада популярлаша барган сүз белән әйтсәк, аномальгә әйләнә бара. Ә шулай да экстрасенсның, «өлешчә корылык көтелә, ә кайбер районнарда, киресенчә, яңгыр ишеп явачак», дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Коры һава торышы аркасында, бодай, арпа уңышы көткән нәтиҗәләрне акламады, бөртекләр бөрешкән районнар да булды. Кайбер якларда дым артык күп булу нәтиҗәсендә, урып-җыю эшләренә керешә алмый тордылар. Шөкер, авыл хуҗалыгы тотрыксыз һава торышыннан әллә ни зыян күрмәде. Икмәк, шикәр чөгендере уңышы да муллан булды.

> *Алсу Газыймҗанова Яңа ел алдыннан, бәйрәм вакытларында һәркемгә юлларда сак, игътибарлы булырга кирәклеген дә искәртте. «Сизәсездер, буран, бозлавык, томаннар булып тора, шуңа да бик кирәк булмаса, юлга чыкмагыз. Чынлап та куркыныч көннәр. Мандариннар белән дә саграк булыгыз, юмыйча ашый күрмәгез», – диде ул.*

Республика медицинасында зур ачышлар ясалачагына аерым басым ясаган иде экстрасенс.

Әлмәттә ачылган югары технологияләр буенча операцияләр ясарга мөмкинлек биргән Идел буе федераль округында бердәнбер гибрид операция бүлеге, Республика клиник хастаханәсе каршында ачылган киң профильле перинаталь үзәк, авыруларны тиз арада тиешле урынга китереп җиткерү өчен кулланыла торган беренче медицина модуле «Ансат» вертолетлары җитештерү... Кыскасы, саный китсәң, медицина өлкәсендә уңышлар җитәрлек. Сәламәтлек саклау министры Адел Вафин әйтүенчә, рактан үлүчеләр санын да быел азга гына булса да киметә алганнар.

Эльвира МОЗАФФАР әзерләде.

Киләсе елга фаразлар

Укучыларыбыз үтенечен искә алып, Алсудан 2017 елга фаразларын сорадык.

– Интригаларга бай, конфликтлы, авыр ел артта калып бара. Киләсе ел тыныч була дип вәгъдә итмим, әмма, узганы белән чагыштырганда, гаделрәк, чагыштырмача уңышлы ел килә, – ди Алсу. – 2017 ел – Әтәч елы. Әтәч – үзсүзле, лидер, гадел, башлаган эшен ахырына кадәр җиткерүче. Россия, Татарстан өчен дә бу ел уңышлы булачак. Фәнни яктан яңа ачышлар, медицина өлкәсендә сөенечле яңалыклар көтелә, мәдәнияттә, спортта яңа исемнәр билгеле булачак. Татарстанда яңа спорт объектлары төзелергә мөмкин. Россия белән Төркия арасында конфликтлар булып торса да, кеше анда ял итәргә барудан туктамас. Ә менә Америка Кушма Штатлары белән безнең ил арасындагы дуслыкка шикләнеп карыйм. Мәгариф өлкәсендә дә реформалар күрәм, алар укырга керү, имтихан бирү процессларын гадиләштерүгә корылган булсын иде дип телисе килә. Халыкның яшәү сыйфаты яхшырачак. Беренче яртыеллыкта авыррак тоелса да, соңыннан икътисадта да тотрыклылык сизелер, кешенең киләсе көнгә ышанычы артыр. Фатир сатып алырга теләүчеләргә исә ашыгырга киңәш итмим. Киләсе елда торак базарында бәяләрнең азга булса да очсызлануын сизәм. Гомумән, өй туйларына бай булачак киләсе ел.

Һава торышына килгәндә, кыш салкын килачәк. Яз көне күп су күрәм. Җәй эссе, урыны белән корылык көтелә. Вакыты белән гарасатлар, яңгыннар чыгуы да ихтимал. Әмма бу бәла-казаларны гадәттән тыш дип кабул итәргә кирәкми, ел да була торган хәлләр. 2017 елда авыл хуҗалыгында яхшы уңыш җыеп алыначак. Фермерларга зур игътибар биреләчәк.

Шунысын да онытмаска кирәк, кешенең киләчәге үзеннән тора. Тормышны үзгәртүне үзеңнән башларга кирәк. Шөкер итеп, һәр аткан таңга сөенеп, исән булуыңа Ходайга рәхмәт әйтеп яшәргә кирәк. Күп нәрсәне тиешенчә бәяләмибез, кадерен белмибез. Әйтик, балалары булган кешеләр аларның нинди зур бәхет икәнен аңлап бетерми. Һәр нәрсәне башкаларныкы белән чагыштырып карарга кирәк. Кемдер гомер буе бала көтә бит. Сүз уңаеннан, быел гаиләләрдә балалар күп туачак, дип күрәм. Кешеләрдә бәйләлек көчле, кемдер компьютер уеннарына бирелгән, кайсы эчкечелектән арына алмый. Бу елда халыкны туганлык җепләрен ныгытырга өндәр идем. Әти-әниләргә хөрмәт белән карау, тарихыңны белү, үткәннәреңне барлау мөһим. Барысы да – бүгенгебез, киләчәгебез дә тамырларыбызга, гореф-гадәтләребезгә бәйле бит. Һәр кеше үзен кайгыртып яшәсен иде!

Разил Вәлиев: «ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ – БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ИҢ ЗУР НӘРСӘ»

Разил Вәлиев – күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, танылган әдип. Әдип дим, чөнки аның эшчәнлеге бик киң, «язучы», «шагыйрь», «тәрҗемәче», «публицист» дип бер сүз белән генә билгеләрлек түгел. Ул – милләт улы, милли әдәбият, мәдәният, мәгариф һәм йөз дә бер башка миллият сораулары тәүлеккә олы йөкне әйдәп тартып баручы кеше.

«МИЛЛӘТ ӨЧЕН ЯШӘҮ – БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ИҢ ЗУР НӘРСӘ»

– Бүген бөтен кеше дә сәясәт белән кызыксына, сәясәтчеләрне мактый, кайберләре сүгә. Шуңа күрә минем күңелдә гел бер сорау бөтерелә: сәясәтче булып туарга кирәкме, әллә бу тәрбия нәтиҗәсеме?

– Аның тегесе дә, монысы да кирәктер инде. Ләкин мин сәясәтче булып тууымны белмим, хәтерләмим. Ә тәрбия турында нидер әйтә алам, чөнки сәясәт аерым бер урын алып торган гаиләдә үстем.

Әнкәй ягыннан бабам авылның иң хәлле кешеләренең берсе булган. Алар гаиләдә биш бертуган, бишесе билне биштән буып эшләгәннәр. Су тегермәне салганнар, ул тегерменгә халык, кырыгар чакрымнан килеп, он тарттыра торган булган. Үзенең сушилкасы бар иде. Ашлык киптерә торган алачыкның иләксыман җиз идәнен бабай Екатеринбургтан алып кайткан, кырык көн кайттык, дип сөйли иде. Тимерчелекләре бар иде, тәрәзә рамнары, тәрәзә кашагалары ясыйлар иде... Әнкәйнең энеләре үзләре гармун ясыйлар, гармун төзәтәләр иде. Кыскасы, алтын куллы кешеләр, белмәгән эшләре юк. Ләкин колхозлашу башлангач, бабайның бар малын тартып алалар. Алар гаиләләре белән мунчада яшәргә мәҗбүр булалар. Калган кәҗә-сарыкларын да көтүгә чыгармыйлар, бәрәңге утыртырга да рөхсәт юк. Ләкин бабайны Себергә сөрмиләр, чөнки аны сөрсәләр, тегермәннең дә, тимерчелекнең дә рәтен белүче юк. Алар хезмәтче дә тотмаганнар, биш бертуган бер булып эшләгәннәр. Бабайны бик яхшы хәтерлим мин, анын янында токарь станогында нәрсәдер эшләүләр миңа гел кызык була торган иде.

Ул гомер буена колхозга, совет властена рәнҗешле булды. «Уртак малны эт ашамас», – дип еш кына әйтә иде. «Тормыш болай бара алмый, кайчан да булса бетәчәк бу колхозлар», – дип тә өстәп куя иде. Гомер буена колхозга кермәде ул. Балаларын да керттермәде. Ә бу колхозның рәисе – минем әткәй иде. Бабай белән әткәй гел бәхәсләшә, әнкәй боларны килештерергә тырышып яши иде. Сәясәткә әкренләп керә башлавым бәлки шунда булгандыр.

Милли мәсьәләгә ныклабрак кереп китүем сигезне бетереп Түбән Камада укый башлагач булды бугай. Рус теленда «Живое седло» дигән китапны укып чыктым, анда «урыс каеннары» дигән сүз бар иде. Бу каен безнең авылда да бар бит, нишләп ул урысныкы булсын, дип уйладым. Ә Казанга килгәч, бу мәсьәлә көннән-көн тирәнәйде, зурайды. Милли мәсьәләләргә күземне ачкан кешеләрнең беренчесе, бәлки, Батулла булгандыр. Ул күп нәрсәләр сөйли, аңлата иде, аның артыннан ияреп йөри идек без.

– Безнең язучылар хәтта фантастик әсәрләрдә дә милли проблемаларга кагылмыйча китә алмый.

– Безнең халыкның язмышыдыр ул, чөнки дәүләтсез халык – ятим бала кебек. Үзен ныклы нигездә итеп тоярга, зур дөньяга чыгарга кыенсынып яши кебек. Ә дәүләтле халык үзен бик иркен тота. Чөнки аңа дәүләте терәк була, ярдәм итә... Ул милләте турында артык уйламый да, чөнки аның милли мәнфәгатьләрен дәүләте кайгырта... Ә без, дәүләтсез халык булгач, бернәрсә дә көтә алмыйбыз. XVIII-XIX гасырларда татарның мәдрәсәләрен дәүләт төземәгән бит. Милли гәзит-журналларын да татар үзе чыгарган. Хөкүмәт аңа мәчет тә, мәктәп тә салмаган. Халык үзенең милли ихтыяҗларын үзе хәл итәргә тиеш булган, шуңа күрә ул үз язмышын милләт язмышыннан аерып карамаган. Бүгенге көндә дә бит урыс чиркәү сала икән – дәүләт ярдәменә өмет итә, татар мәчет сала икән – халыктан акча җыя. Үз язмышыбызны үзебез хәл итәргә кирәк булганга күрә, безнең аңыбызга милләт белән бергәлек бик нык сеңгән. Без үзебезне элек-электән беренче чиратта дәүләт кешесе дип түгел, ә милләт кешесе буларак кабул иткәнбез. Шуңа күрә безне милләт язмышы бик нык борчый.

– Ул бөтен кешене дә борчымаган төсле...

– Бер караганда гына борчымаган төсле тоела ул, гади кеше милләт турында уйламаган да кебек. Ләкин, ни әйтсәң дә, һәр татар кешесе диярлек милләтенә үзеннән күпмедер өлеш кертеп яши... Җитмеш тугызынчы елны без авылыбызда мәчетне төзәттек. Ул вакытта совет чоры, минем Казанда китабым чыккан иде. Шуның гонорарына мәчет манарасын торгызырга, түбәсен рәтләргә булдык. Мин шунда авыл халкының ярдәмчеллегенә шаккаттым. Кемдер такта, кемдер кадак күтәреп килә, кемдер бәрәңге пешереп килә... Мин моңа кадәр үзебезнең авыл халкын белмәгәнмен икән... Ул колхоз эшенә бара да эштән кайта, аңа бүтән берни дә кирәкми, дип уйлаганмын. Юк, ул үзебезнең милләт турында, аның дине, йолалары турында да уйлый икән... Менә шуңа күрә мин татар кешесе, бигрәк тә татар язучысы, үз халкыннан, үз милләтеннән аерыла алмый дип исәплим.

– Һәр татар үзе дә бер дәүләт шикеллерәк бугай.

– Казан ханлыгы алынганнан соң, исән калган халык төрле җирләргә таралган, тора-бара яңадан авылларда төпләнеп оешкан. Ни өчен татар авылы һәрчак мәгърифәтле булган? Чөнки менә шушы кешеләр ул авылларга шәһәр мәдәниятен дә алып килгәннәр. Монысы бер. Аннан соң, һәрбер татар авылы Казан ханлыгы егылганнан соң бәләкәй генә бер дәүләткә әверелгән. Безнең авылның да үзенең «патша» кебек бер кешесе бар иде, аңа карап кына торалар иде. Авылның үз идеологы, үз композиторы бар иде. Хәтта үз архивисты да... Бөтен тарихи мәгълүматларны җыеп бара торган кешесе. Зур дәүләттә нәрсә булырга тиеш, безнең авылда аның һәммәсе дә нәни генә вариантта бар иде. Алай гына да түгел, авылның үз чикләре, авыл капкасы да бар иде. Читтән кемдер килсә, капканы ул үзе ачып кереп китми – авыл читендә яшәгән кеше аны уздыра торган иде. Кеше авылдан бик ерак китмәскә өйрәнгән иде. Без шушы авылда, үзебезнең дәүләтебез эчендә яши идек. Шушы нәни дәүләтебез безнең терәгебез дә, таянычыбыз да, юанычыбыз да булды.

Үзебезнең милләт өчен яшәү – безнең өчен иң зур нәрсә. Мәшһүр язучыбыз Туфан абый әйтә иде: «Мине чит илләрдә танып та үз халкымда, үз авылымда танымасалар, үземне яхшы язучыга, бәхетле язучыга санамас идем». Олы халык язучысы шулай дигәч, юкка түгелдер инде бу...

– Бездә төрле өлкәдә талантлы кешеләр бик күп, әмма аларның исемнәре дөньяга чыкмый, үз эчебездә бикләнеп яшәгән кебек.

– Мин моның сәбәбе дөньяга чыгаручыбыз булмауда дип уйлыйм. Менә Мостай Кәримне яки Рәсүл Гамзатовны дөньяга кем чыгарды? Үз республикалары бит! Аларның республикалары да безнеке кебек иде югыйсә, әмма безгә, татарларга, Мәскәүдә аерым бер мөнәсәбәт... Ә дөньяга чыгарырлык олуг әдипләребез бар безнең.

– Шулай да без бөтен дөньяга танылган үз татарларыбыздан бераз читләшәбез кебек. Аларны үзебезнеке итеп карау җитеп бетмиме, үзебезне бербөтен милләт итеп тоюмы... Шул ук Рудольф Нуриев, мәсәлән...

– Рудольф Нуриевлар безнең халыкка хезмәт итә алмадылар инде. Дөнья сәнгатенә хезмәт иттеләр. Алар монда булсалар, бәлки, ул кадәр үк танылмаган да булырлар иде, чөнки үз илләрендә аларга мәйдан булмады. Читкә киткәч, бездә аларны бик күтәрергә тырышмыйлар, читтә эшләгәч, аларның безнең мәдәнияттә, әдәбиятта әллә ни өлешләре дә юк шикелле. Ләкин исемнәре бар. Бер генә мисал китерим. Универсиада вакытында татарның мәшһүр шәхесләре турында, Татар ПЕН-үзәге көче белән, «Кырык татар» дигән китап чыгарган идек. Без аны Универсиадага килгән кунакларга тараттык. Бер кунак, бик атаклы кеше инде бу, моны миңа ник бирдегез инде дигән шикелле, китапны бик битараф кына актарып утыра. Һәм бервакыт Нуриев битенә килеп җитте дә: «Нуриев та татармыни?!» – диде. Аннары башка татарларны да карый башлады. Һәм китапны кадерләп, сумкасына салып куйды.

Ә без бит бу очракта Нуриевны гына күтәрмибез. Без үз халкыбызны күтәрәбез булып чыга. Халкыбыз – шәхесләребезне, шәхесләребез халкыбызны күтәрергә тиештер.

«ЭЛЕК БЕЗ БИТАРАФ ТҮГЕЛ ИДЕК»

– Бүген әдәбият ятим бала хәлендә: дәүләт тарафыннан да, халык тарафыннан да аңа игътибар аз сыман. Бу нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?

Гыйнвар аенда Разил Вәлиев үзенең 70 яшьлек юбилеен каршылый. Аны «Шәһри Казан» газетасы коллективы һәм укучыларыбыз исеменнән дә бәйрәме белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Сәламәтлек, күңел тынычлыгы һәм иҗат илһамы телибез сезгә, Разил әфәнде! Эшләрегез уңышлы булсын!

КЕШЕЛӘРГӘ КИРӘК БУЛУДА»

– Бу бик зур фаҗига, афәт бүгенге көндә. Безнең халыкның гына түгел, теләсә кайсы халыкның да фаҗигасе. Мәсәлән, урыс бит инде дәүләтле халык, зур халык, бөтен яклап та аның мөмкинлекләре күп. Әмма Распутиннардан соң аның да бит зур язучылары күренми. Димәк, кирәк түгел. Кирәк булмаган нәрсә беркайчан да үсеп китә алмый. Безнең дәүләт әдәбиятны бүген бик үк кирәк дип санамый кебек, чөнки бүгенге көндә Россия конституциясе буенча да, яшәү халәтебез буенча да дәүләтебезнең анык бер идеологиясе юк. Идеологиясе булмагач, күңелгә иңдерерлек милли фикере дә юк, аны индерергә ашкынып торган кеше дә юк. Язучының гына түгел, бүген, гомумән, иҗат кешесенең бәясе бик түбән төште. Бу бер безнең илдә генә түгелдер дип уйлыйм…

– Башка илләргә кагылганда… Менә Америка бар. Ул әдәбиятның һәм кинематографиянең бөтен юллары белән үз идеологиясен безгә сеңдерергә тырыша.

– Чөнки аларның дәүләт идеологиясе бар. Американың иң төп идеологиясе – дөньядагы иң көчле держава булу, дөньяны үз кулында тоту. Шуңа күрә Америка кешесе ул әдәбиятта да, сәнгатьтә дә супергерой, ул – бөтен дөньяда беренче. Аларның суперидеологияләре шул – без иң көчле, без иң бай, без иң бәхетле… Бездә аңа охшаш идеология юк. Бездә – үз-үзебезне саклау идеологиясе. Ничек кенә булса да, исән калу, сугыш кына булмасын, халык күтәрелеп чыкмасын, баш күтәрмәсен… Бу тәрәкъкыяткә илтә торган идеология була алмый.

– Элек дөнья күргән һәр әсәр турында матбугатта чыгышлар була, дөнья шаулап тора иде. Бүген шедевр язсаң да, өч тиенлек нәрсә әтмәлләсәң дә, беркем берни дәшми. Ниндидер битарафлык хөкем сөрә кебек.

– Битарафлык бар. Менә без, язучылар, үзебез бер-беребезне укыйбызмы? Мин әле шушы көннәрдә генә Ләбиб Леронның яңа кулъязмасын карап чыктым. Аның белән даими аралашып яшим, пародияләрен укыйм, спектакльләрен караганым бар. Нигездә, юморист, сатирик дип күз алдына китерә идем мин аны. Лирикасын укып караган идем – шактый әйбәт шагыйрь икән бит ул. Белмәгәнмен. Ә элегрәк без андый түгел идек… Бер-беребезне даими укый идек, яңа язган әсәрләрне һәрчак бер-беребезгә укыша, бәхәсләшә идек… һәрдаим әдәби кичәләр уза, анда халыкка урын җиткереп булмый иде… Ә бүген? Каян килде бу битарафлык? Бездәге битарафлык халыкка күчәме, халыктагы битарафлык безгәме – аңламассың.

– Ә бәлки ул читтән сеңдереләдер?

– Әле беркөнне генә дустым белән сөйләшеп утырдык. Телевизорны ачабыз, ди, тегендә йөз кеше үлгән, монда шартлатканнар – шул хәтле кеше үлгән, анда бу хәтле кеше үлгән… Сөйли, күрсәтә торалар, ә без карый торабыз, чәй эчеп утырабыз, ди. Тегендә адәм балалары кырыла, ә без монда тәмләп чәй эчәбез. Бездә хәзер меңләгән кеше үлеме дә гадәти хәлгә әйләнә. Без шулай аптырау, шаккату, нәфрәтләнү һәм соклану хисен югалтабыз. Ә бу хисләрне югалткан кешедә әдәби әсәрләр уку ихтыяҗы да юкка чыга. Чөнки битараф кешегә әдәбиятның, сәнгатьнең кирәге калмый. Һәм без бүген яшь буынны шулай тәрбиялибез…

«ЧҮПЛӘМӘГЕЗ ӘДӘБИЯТНЫ»

– Сезнең эшчәнлек бик тә киң – сәясәтче, язучы, шагыйрь, тәрҗемәче һ.б., һ.б… Ә үзегезгә боларның кайсы якынрак, сез үзегезне кем дип исәплисез?

– Аны инде башкалар әйтергә тиештер. Тик мин шигырьне барыбер беренче урынга куям. Туфан абый минем проза әсәрләрен укыгач, болай дип әйткән иде: «Син традицион прозаик түгел, шагыйрь-прозаик». Минемчә, һәр язучы шигъри образлы фикерләүгә ия булырга тиештер.

– Хәзер мин сезнең «Күренекле шәхесләр белән әңгәмәләр»егездә башка язучыларга биргән сорауларыгызны үзегезгә юнәлтәм. Язучылык оеткысы, мәгърифәтчелек дәрте сезнең күңелгә кайда һәм кайчан салынды икән?

– Ул кешеләргә үз сүзеңне, үз фикереңне әйтәсе килүдән яралгандыр инде. Кеше белән аралашасы килә, башында фикерләр җыела һәм аларны кемгәдер җиткерәсе килә. Кечкенә чагымда әнкәйнең туган көненә багышлап бер шигырь яздым. Дүртьюллык кына иде ул. Апам открытка урынына рәсем ясады, мин шул шигырьне укыдым. Әй әнкәйнең күзләреннән яшьләр килде инде, әй шаккатты, әй сөенде инде! Шушы сөенеч күңелгә шигъриятнең бер орлыгы булып кереп калды. Аннан дусларга багышлап яза башладым. Шуннан мәкалә яздым. Монысы инде кайчандыр азып-тузып йөреп, хәзер инсафлы кеше булып гел акыл сатып йөри торган бер авылдаш абзый турында иде. Шуны берничә көннән район газитендә бастырып чыгардылар. Моның малайлары клубтан кайтканда тотып тукмадылар мине. Шуннан бирле мине гомер буе ике нәрсә озатып йөри: мактасаң – яраталар, хурласаң – тотып тукмыйлар. Шушы нәрсәләр мине әдәбиятка алып кереп китте – кешегә әдәби әсәр белән тәэсир итүдән дә яхшырагы юк икән диган фикер күңелгә кереп оялады.

– Ялгыз калып уйланганда…

– Мин ялгыз калырга яратам. Үз илемдә, якыннарым арасында. Ләкин чит җирләрдә бер ялгызым калсам, бик моңсу була. Монда беркемем дә юк бит дип курка, шомлана башлыйм.

– Үткән гомерегезнең кайсы еллары бигрәк тә кадерле, кайсы елларын бигрәк тә сагынасыз?

– Яшьлекне уйламый мөмкин түгел… Ә инде бала чагымны… Аның да матур чаклары бар иде… Минем иң күңелле вакытларым Түбән Камада укыганда, интернатта торганда булды бугай. Әмма язмышыма иң нык тәэсир иткән чор Мәскәү булды. Анда мин беренче тапкыр азмы-күпме хөрриятне сиздем. Ул хөр фикерне белдерергә, сиздерергә омтылганда ялгышкан очракларым да булгандыр. Листовкалар таратып йөргән чакларымда ярый әле ректорыбыз һәм укытучыларым яклап калды. Лев Ошанин минем өчен бик өзелеп йөрде. Ректор да… Аның сүзләре әле бүген дә колагымда кебек: «Запомни на всю жизнь, это – литературный институт, здесь не политикой занимаются, здесь поэтикой занимаются». Менә шул рәвешле Мәскәү мәктәбе миңа бик күп нәрсә бирде.

Ә яшьлекне сагыну ул гадәти хәлдер инде. Яшьлекне сагынам мин. Гашыйк булып, көнәнә бишәр-алтышар, җидешәр-сигезәр шигырь язган чакларны. Бер тыелгысыз иҗат чоры иде ул. Һәм тагын бер сәерлегем бар, кайбер шагыйрьләр мине аңламыйлардыр инде. Зинһар өчен, шигырь язмагыз, дим аларга. Чүпләмәгез әдәбиятны. Җитмеш-сиксән яшьтә сүрән хисле мәхәббәт шигырьләре язу… минем өчен сәер тоела… Алтмыш-җитмештән соң инде прозага күчәргә кирәк. Тормыш тәҗрибәң бар, күпне күргәнсең… Поэзияне яшьләргә калдырыйк… Ә сез яшь чакта язган шигырьләрегез биеклегендә калыгыз.

– Сезнең шигырьләргә бик матур көйләр язылган. Шулар арасыннан халык күңеленә мәңгелеккә уелып калырдайлары да шактый. Ә үзегезгә аларның кайсысы аерата якын, аерата кадерле?

– Җыр ул кечкенәдән күңелгә кереп калган. Без бәләкәй чактан ук инде Алмаз Хәмзин белән мәктәптә концертлар куеп йөри идек. Туганнарым да җырлы-моңлы кешеләр, үзем дә бераз гармун тартырга өйрәндем. Мәктәптә бик яхшы хор бар иде, аның җырчысы да булдым. Җыр һәрчак күңелдә бар иде. Ләкин җыр иҗат итү мәсьәләсендә иң зур сабакны Илһам Шакиров бирде. «Бер алманы бишкә бүләек» җырында «кар аклыгы гөлгә күчкән» диган юл бар иде. Илһам абый бик яраткан бу шигырьне, тик бер юлың бик үк дөрес түгел, җырлаганда ул «караклыгы гөлгә күчкән» булып ишетелә дигәч, «кыш аклыгы гөлгә күчкән» дип үзгәрттек. Иҗекләр, сүзләр яңгырашында бөтенләй көтелмәгән мәгънә бирә торган очраклар була икән. Илһам абый шулардан арынырга өйрәтте.

Тагын бер нәрсә бар. Бүгенге көндә халык күңеленә барып җитәм дисәң, иң үтемле жанр – җыр. Җырны машинада да, ашап утырганда да тыңлап була. Бөтен җирдә тыңлап була.

– Сез инде тормышның ачысын-төчесен татыган олпат кеше. Эшләгән эшләрегез, тормыш тәҗрибәгез дә зур. Менә сез бүген, 70 яшегез тулган көннәрдә, яшәүнең, тормышның мәгънәсе нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Кешеләргә кирәк булуда… Үзеңнең, иҗатыңның, кылган гамәлләреңнең халыкка, кешеләргә кирәк булуында…

Әңгәмәдәш –
Марат КӘБИРОВ.

«Яхшылыкның зурысы һәм кечкенәсе юк»

Актанышка барабыз, юл озын. Күңелдәге бөтен йомгакларны сүтеп, хәтер сандыгын актарырга вакыт җитәрлек. Ниндидер эшләр, очрашулар искә төшә... Алар арасында уйлап, планлаштырып йөреп тә, башкарылмыйча калган игелекле эшләр дә аз түгел. Телевизордан әледән-әле өзгәләнеп авыру баласына ярдәм сораучы әти-әниләрне күрсәтәләр. Чын күңелдән, аз гына булса да ярдәм итим, дип тотынасың да, нииндидер каршылык чыгып тукталып кала, аннан соң онытылып та китә.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Автор фотосы

Якыннарыбызның, ялгыз танышларыбызның хәлен белергә кирәк дип йөреп тә атна-ун көн узганы сизелмичә дә үтеп китә. Югыйсә авыру кешенең хәлен белү дә бик зур савап икәнен барыбыз да белә. Ярый да әле безнең янәшәдә башкаларга ярдәм итүне үзләренең тормыш формуласы итеп алган кешеләр бар. Актаныш районында яшәүче «БлагоДарение» хәйрия фонды президенты Фәрит Салихов әнә шундыйлардан. Аның кебекләр бүгенге җәмгыятьтә күп түгел, ә алардан ярдәм сораучылар бихисап. Әңгәмәдәшемә беренче соравым да нәкъ әнә шул турыда булды.

– Фәрит Муллагалиевич, сезгә мөрәҗәгать итүчеләр бик күптер. Шулар арасыннан беркемне дә рәнҗетмичә, мохтаҗын сайлап алу иң авырыдыр сыман.

– Барыбыз да күрәбез: ярдәм сораучылар бүген бихисап. Кемнәрдер чыннан да мохтаҗ, ә икенчеләре бик кыю, кайчакта артык әрсез дип тә әйтергә була. Әлбәттә, һәрбер мөрәҗәгать итүчегә ярдәм итеп булмый. Без аларның һәркайсының авыру тарихын, сәламәтләнә алу мөмкинлеген ныклап өйрәнәбез. Кайчакта бик аз гына чыгымнар белән дә баланың савыгып китүенә ярдәм итә алганыңа куанасың, икенче юлы зур күләмдә акчалар бәрабәренә дә бернәрсәне дә үзгәртеп булмаганны аңлыйсың. Әти-әниләргә баладан да газиз кеше юк, әлбәттә, алар, әз генә өмет булса да, аны кулланып карарга тырышалар. Үзебез ярдәм кулы суза алырдай балаларны чиратка куябыз һәм мөмкин хәтле ярдәм итәбез.

– Кайчак, хәйриячелек дигәндә, теге яки бу авыру балага акчалата ярдәм итүне генә күзаллыйбыз кебек.

– Әйе, шулайрак килеп чыга шул. Ә чынлыкта исә хәйриячелекнең бик күп юнәлешләре һәм алымнары бар. Безнең «БлагоДарение» фонды яшь буынга һәм социаль инициативаларны тормышка ашыруда ярдәм итүне максат итеп куя.

– Ярдәмең белән икенче берәүнең, бигрәк тә зур тормышка аяк басып килүче яшь кешенең язмышын уңай якка үзгәртеп җибәрә алу зур бәхеттер.

– Баулыдагы «Шатлык» тернәкләндерү үзәгенә йөрүче Руслан Евстифеев белән таныштык. Ул бик актив егет, барлык чараларда катнашырга тырыша, аның хыялы фотограф булу икән. Без аңа профессиональ фотоаппарат алып бирдек һәм остаз белән мастер-дәресләр оештырдык. Баулының Муса Җәлил исемендәге мәдәният йортында Русланның беренче күргәзмәсе оештырылды инде. Киләчәктә исә бу аның һөнәре булырга да мөмкин. Яки тагын бер очрак. Шушы ук үзәктә Екатерина Кулагина исемле кыз белән таныштык. Ул шигырь һәм чәчмә әсәрләр яза. Аның иҗаты белән танышкач, фикер тирәнлегенә хәйран каласың. Узган ел Екатеринаның китабын бастырып, аны тәкъдим итү кичәсен үткәрдек. Моннан соң китап бастыруны сорап мөрәҗәгать итүчеләр күп булды. Бик талантлы булсалар да, без һәрбер шигырь язган кешенең китабын бастыра алмыйбыз. Зур сынаулар үтеп тә, күңел матурлыгын җуймыйча, бирешмим, дип яшәргә тырышучы Екатерина Кулагинага бу ярдәм башкаларга караганда ныграк кирәк булгандыр дип уйлыйм.

– Кайчак кешеләргә карата булган игътибар, җылы сүз дә әллә нинди дәвалардан да артыграк булып куя. Күпләрнең күңелендә яхшылык эшлисе килү теләге яши, күпвакыт мөмкинлеген, вакытын табып кына бетерә алмыйлар кебек.

– Безнең «БлагоДарение» фондының бер максаты да шундый: яшьләрнең күңелләренә игелеклелек орлыклары салу, янәшәдәгеләрнең уй-борчуларына карата игътибарлы, ярдәмчел булу. Яхшылык кылу теләге кеше күңелендә әледән-әле кабынып кына калмыйча, гел шунда яшәргә тиеш. Яхшылык, игелек кылуның зурысы һәм кечкенәсе юк. Әнисе үз эшләре белән йөргәндә, авыру бала белән урамга чыгып йөрү яки колясканы кертергә, чыгарырга булышу… Ялгызларның, картлар йортында яшәүчеләрнең хәлен белү. Без үзебезнең проектлар белән кешеләрне янәшәбездә яшәүчеләргә карата игътибарлырак булырга өндибез.

«Шәһри Казан» газетасы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ирек Салиховның «БлагоДарение» яшь буын һәм социаль инициативаларга теләктәшлек күрсәтү хәйрия фонды белән берлектә, «Әти хакы» дигән бәйге игълан итә.

Җәмгыятьтә Әти ролен күтәрүгә, үрнәк гаиләләрне барлауга юнәлтелгән бәйгедә теләге булган һәркем катнаша ала. Моның өчен Әтиләрне данлаган язмаларны «Шәһри Казан» редакциясенә юлларга кирәк. Шигырьләр кабул ителми. Җиңүчеләрне фонд вәкилләре һәм газета хезмәткәрләре кергән жюри билгели. Конкурста 3 номинациядә 3 җиңүче бүләкләнә. Җиңүчеләр, әтиләре белән бергә, Казанга чакырыла. **БҮЛӘККӘ – ӨЧ ВЕЛОСИПЕД!**

Номинацияләр:
«ҮРНӘК ӘТИ» – *әтиләр турындагы иң яхшы язма*
«ОЛЫ ЙӨРӘКЛЕ ӘТИ» – *тәрбиягә алынган балаларны тәрбияләүче гаиләдәге әтиләр турында иң яхшы язма*
«БАТЫР ӘТИ» – *ялгыз гына бала үстерүче, үстергән әтиләр турында иң яхшы язма*

Язмалар **2016 елның 12 декабреннән 2017 елның 31 мартына** кадәр кабул ителә.
Тулырак мәгълүмат **shahrikazan.com** сайтында

12+

«Балалар ятимлекне тоярга тиеш түгел»

Гадәттәгечә, быел да Яңа ел алдыннан Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Казан шәһәре бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов Яшел Үзән районындагы Норлат балалар йортында тәрбияләнүчеләрне бәйрәм белән котларга кайтты.

Әлеге ятимнәр йортында 50гә якын бала тәрбияләнә. Алар күптәнге дуслары – хәйрияче Фәрит Мифтаховны аеруча сагынып көтеп алалар икән. Кунаклар өчен махсус концерт программасы да әзерләгәннәр. Фәрит әфәнде дә үз чиратында балаларга яраткан җырларын бүләк иткән (Фәрит Мифтахов башкаруындагы җырны shahrikazan.com сайтыннан карый аласыз), Яңа ел күчтәнәчләре тапшырган.

– Кеше тирә-юньдәгеләргә кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яшәргә тиеш дип саныйм. Норлат балалар йорты белән күптәннән тыгыз элемтәдә торабыз. Ятим балалар назга, игътибарга мохтаҗ. Без күчтәнәчләр тапшырырга гына түгел, алар үзләрен башкалардан ким хис итмәсеннәр, башкалар белән бер дәрәҗәдә гомер итүләрен аңласыннар өчен дә киләбез. Балалар ятимлекне тоярга тиеш түгел, – ди Фәрит Мифтахов.

Норлат балалар йортының директоры Дамир Рәхмәтуллин исә: «Фәрит Мифтахов – яшәүнең һәр мизгеленнән рухи ләззәт алып яши белгән изге күңелле җитәкчеләребезнең берсе. Аның безгә кунакка килүе – сабыйлар өчен зур бәйрәм! Балаларга кечкенәдән туганлык җепләренең кадерен белергә, яшьләрне имин гаилә тормышына, рухи кыйммәтләрне бәяләргә өйрәтергә кирәк. Әлеге мәсьәләдә бу очрашулар нык ярдәм итә», – ди.

Кунак ашы – кара-каршы дигәндәй, Норлат балалар йортында тәрбияләнүчеләр шушы көннәрдә үзләре дә Тынычлык бистәсе мәдәният йортына Яңа ел тамашасы карарга килгәннәр иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Ялгызлык утында янмагыз

Бер укучыбыз ким дигәндә атнасына өч-дүрт тапкыр шалтыратып хәлебезне белешә. Хәл белешеп кенә калмый, көн диме, төн тиме, кунакка чакыра. Менә тагын шалтыратты. «Ялгызлык – үлемнән дә яман. Кил инде бер, чәй эчеп, сөйләшеп утырырбыз», – ди, ялварып.

Эльвира МОЗАФФАР

ӘБИГӘ ИПТӘШ КИРӘК

Аның янына берничә тапкыр бардым инде. Моннан җиде-сигез еллар элек ул Киров районында яши иде. Әби белән сәгатьләр буе аның фәнни эшләре, яшьлек еллары, гаиләсе турында сөйләшеп утырган идек. Соңрак аңа, үзе әйткәндәй, «зур урында» эшләүче балалары шәһәр үзәгеннән бер бүлмәле фатир алып бирделәр. Хәзер әби шунда яши. Урамга чыгып йөри алмый, өй телефоны юк. Ни хикмәт, кесә телефонына да акча салучы юк, күрәсең: ул шалтыраткан саен, оператор кыз «сөйләшү сезнең исәпкә булачак» дип кисәтә. Яңа фатирына күчкәч тә чакырган иде. Ул чакта ишекләрне бикләп куеп, чыгармый җәфалаган иде. «Сөйләр сүзләр бетмәде», – дип, кунып калырга кыстады. Шуннан соң башка бармадым. Хәлен телефоннан гына белешеп торам.

Берсендә таң белән телефон шалтыраганга куркып уянып киттем. Әлеге дә баягы яраткан әбиебез икән. Берәр хәл булганмы дисәм, тагын үз туксаны туксан. Кунакка чакыра. «Ялгызлыктан тилмерәм», – ди. «Балаларыгыз, оныкларыгыз бар лабаса, ник аларны дәшмисез, ник алар белән сөйләшмисез?» – дим. «Юк, аларны борчырга ярамый, алар дәрәҗәле кешеләр», – дип гаҗәпләндерде. «Картлар йортына урнаштырырга ярдәм ит», – дип тә сораганы бар әбинең. Аена 150 сум түләп кенә берәр студент кыз кертәм дип газетага игълан бирергә дә кушкан иде. Кыскасы, әби чәй табыны артында рәхәтләнеп сөйләшеп утырырга, эч серләрен бүлешергә бер иптәш эзли.

«АКЧА БИРСӘМ, ДОГА КЫЛЫРСЫҢМЫ?»

Икенче бер укучыбыз – шулай ук ялгызы гына яшәүче бабай. Алты баласы бар-барын, тик тормыш иптәшен җирләгәннән соң, чын мәгънәсендә япа-ялгыз калды бабай. Балалары белән элек тә дә юньләп аралашмаганнар. «Уртак тел таба алмадык, мине яратмыйлар», – ди. Үзе гомер буе акча җыйган. Пенсиясен дә банктагы исәп-хисап счетына күчереп барган. Туплый торгач, шактый җыелган. Хәзер менә 90 яшеннән узган бабай ул акчаларны кая куйыйм икән, дип баш вата. «Балаларыгызга бүлеп бирегез», – дигән фикеремне дә хупламады.

– Аларга мин кирәк түгел. Мине карамыйлар, яныма килеп хәлемне белмиләр, ник мин аларга гомер буе җыйган хәләл акчамны калдырырга тиеш?! – ди.

Хәер, балалары әтиләре янына килеп караган. Тик акча турында сүз чыккач, очрашу бәхәс, «ашыгыч ярдәм» хезмәте чакырту белән төгәлләнгән. Бабайның йөрәк өянәге тоткан. Шулай да байлыкны үзең белән теге дөньяга алып китеп булмаганны аңлаган, күрәсең. Акчасының яртысын балаларына бүлеп биргән, тик бер шарт белән: балалар атна саен әтисе белән әнисен искә алып дога кылырга, мәчеткә сәдака бирергә, Коръән ашлары уздырырга тиеш.

Ялгыз кешеләрнең иң күбесе Японидә икән. Биредә аларның тормышын уңайлы итәргә тырышалар. Әйтик, берүзе генә яшәүче кешеләр өчен кибетләрдә яшелчәләрне кечкенә капларда саталар. Алар өчен махсус роботлар да уйлап чыгарганнар. Роботлар хәрәкәтләнә, сине көннәр буе тыңлап утырырга да әзер. Хәтта «ашыгыч ярдәм» хезмәте дә чакырта беләләр. Безнең укучыларыбызга да ярап куяр иде бу робот-иптәшләр…

«Бар дөнья утында яныгыз, ялгызлык утында янмагыз», – дип җырлыйлармы әле? Ялгыз калу чынлап та яман. Кеше күңелендәге бушлык ялгызлыкка китерә, ди психологлар. Хәтта парлы кешеләр дә, тиешле игътибар булмаса, үзләрен ялгыз хис итә. Ялгызлар башкалардан читләшергә, үз эченә бикләнергә мөмкин.

– Мөселман кешесе беркайчан да ялгыз булмый, – ди Татарстан Диния нәзарәтенең пропаганда бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров. – Аллаһы ялгыз булмаган кешенең дә иң якын иптәше булырга тиеш, ә берүзе калган кеше намазга басса, дингә килсә, догалар кылса, Аллаһы аның иң якын дустына әйләнәчәк. Дин буенча, балалар әти-әнине хөрмәт итәргә, картаймыш көннәрендә тәрбия күрсәтергә тиешләр. Безнең бәхетебез әти-әнинең изге догасына бәйле. Пәйгамбәребез (с.г.с): «Әүвәл миңа шөкер кылыгыз, аннары әти-әниегезгә шөкер кылыгыз», – ди. Әти-әнигә хөрмәт күрсәтелмәсә, бер генә изге гамәл дә файда китермәс. Әти-әнигә мөнәсәбәт нинди булса, безнең балалардан үзебезгә карата да шундый караш булыр. Коръәндә шундый сүзләр бар: «Байлык, балалар – сынау». «Балалар – тормышның бизәге» дигәне дә бар. Сабыйлар тормыш бизәгенә әйләнсен өчен, без аларга дөрес, дини тәрбия бирергә тиеш. Аларның киләчәген кайгыртам дип, Аллаһыны онытырга ярамый.

Исламия МӘХМҮТОВА, ***Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты:***

– Берүзем яшәсәм дә, үземне ялгыз дип әйтә алмыйм. Актив тормыш алып барам. Балалар, оныклар белән еш аралашабыз. Сеңлем Рузия белән сөйләшеп туя алмыйбыз. Сәхнәдә дә уйныйм бит әле. Яраткан тамашачыларым бар, алар хәлемне гел белеп торалар. Ә менә Хәлилне юксынам. Ул гел исемдә. Догалар уку ярдәм итә. Ялгыз калганнарга үз эчләренә бикләнмәскә, күбрәк аралашырга киңәш итәм. Кәрим Тинчурин театрында нәкъ менә балалары була торып та, картлар йортында яшәргә мәҗбүр карчык тарихын чагылдырган «Ефәк баулы былбыл кош» спектаклен карасыннар. Бик гыйбрәтле әсәр.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ, ***академик, шагыйрь, бакчачы:***

